ӨСТЕНДӘ ТУЗСЫН

Узган айда пальто, куртка кебек өс киемнәре 30 процентка кыйммәтләнгән

> 6

ӘНИ ДОГАСЫ

Алар һәркөн бер теләктә: балам гына исән-сау булсын!

> 17

ӘЛФИЯ МИҢНУЛЛИНА:

«Бәлки кайбер очракта дәшмичә калырга да кирәктер»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 154 (29121) | Җомга | 20 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

СӨТ УРЫНЫНА – ИТ

ТАТАРСТАНДА СЫЕРЛАР САНЫ НИК КИМИ?

Ел башында хуҗалыклар тапшыра торган сөт бәяләре төшкәч, чын нәтиҗәне көзен күрербез, дигән идек. Беренче нәтиҗәләр буенча авыллардан кайтавазлар килә башлады. Кызганыч, алар бер дә сөендерми. Августта сөт хаклары бераз өскә таба үрмәләсә дә, узган елгы күрсәткечләрне барыбер куып тота алмады. Халык сыерларын бетерү яки киметүне дәвам итә. Төп сәбәпләрнең берсе сөт хаклары төшү булса да, аңа башкалары да өстәлә. Алар нинди? Аннан чыгу юлы бармы? Без шуны белештек.

> 5

Ишетми калмагыз

Россия Президенты Владимир Путин 2024 елны Спорт елы дип игълан итү тәкъдимен хуплаган. «RT» агентлыгы хәбәренә караганда, дәүләт башлыгы шулай ук Кызыл мәйданда спорт парадларын яңартып җибәрү тәкъдиме белән дә килешкән. Исегезгә төшерәбез: киләсе елның 12–23 июнь көннәрендә Казанда БРИКС уеннары үткәреләчәк. Алар илнең спорт календарена кертелгән дә инде. Моннан тыш 2024 елда Татарстан башкаласында БРИКС дәүләтләре башлыклары очрашуын уздыру күздә тотыла. Чараны әзерләү һәм үткәрү өчен республика оештыру комитеты булдырылган. Аңа Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкчелек итә.

Киләсе елда «Москвич»та 50 мең машина җитештерүне күздә тоталар. Автомобиль заводы директоры Александр Мигаль әйтүенчә, бүгенгә 25 меңгә якын машина эшләп чыгарылган. Исегезгә төшерәбез: 4 сентябрьдә Мәскәү мэры Сергей Собянин «КАМАЗ» генераль директоры Сергей Когогин белән «Москвич» заводында яңа модель җыюны тантаналы төстә башлап җибәрде.

Казанда быел октябрь аенда Россия Кораллы Көчләре белән контракт төзегән ир-егетләргә 200әр мең сум акча түләнәчәк. Акча махсус хәрби операциядә катнашу өчен 11–25 октябрь чорында контракт имзалаган Казан егетләренә бер тапкыр бирелә. Билгеле булганча, контракт имзалаган кешегә Россия Оборона министрлыгы бер тапкыр 195 мең сум күләмендә акча түли. Моннан тыш, Татарстанның ДОСААФ оешмасы аеруча кирәкле белгечлек юнәлешләренә өстәмә 105 мең сум акча бирә. Махсус хәрби операция зонасында айлык хезмәт хакы исә 204 мең сумнан башлана.

Татарстанда суыта. Елларда да явым-төшем, көчле җил ихтималы сакланып калачак. КФУ Экология һәм табигатьтән файдалану институтының метеорология кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев әйтүенчә, һава температурасының төшүе көн озынлыгы кыскаруга бәйле. Шул ук вакытта белгеч октябрь ахырында беренче кар төшәчәген билгеләп үткән. «Норма буенча, 17 ноябрь тирәсендә җиргә кар ятарга, даими кар катламы барлыкка килергә тиеш. Ә беренче кар бездә гадәттә октябрь ахырында ява. Аңа күп калмады инде», – дигән ул. Гидрометеоүзәк мәгълүматлары буенча, елларда республикада яңгыр, урыны белән юеш кар, төнге сәгатьләрдә һава температурасының –3 градуска кадәр төшүе көтелә. Синоптикларның башлангыч фаразларына караганда, дүшәмбе – 23 октябрьдә янә яңгыр һәм юеш кар булыр дип көтелә. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +1...+6 градус күрсәтәчәк. Төнлә 0...–4 градуска кадәр салкынайтачак.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

«Зеленый щит – 2023» акциясе кысасында «Татнефть» предприятиесе хезмәткәрләре районда 146 гектардан артык мәйданда агач утырта. Узган еллар белән чагыштырганда бу күрсәткеч 4 тапкыр диярлек арткан. 103 гектарда эш башкарылган инде. Яхшырак үсеп китсен өчен, агачларга шунда ук су сибелә. 5 ел дәвамында аларның үсешен «ТАНЕКО» һәм урманчылык хезмәткәрләре контрольдә тотачак. Проектны гамәлгә ашыру башланганнан бирле нефть эшкәртүчеләр Түбән Кама урманчылары белән берлектә 764 гектардан артык мәйданда 3 миллионнан артык агач утыртты.
(tat.e-nkama.ru)

Зәй

16 октябрьдә көзге чакырылышта беренчеләрдән булып районның ун егетен әти-әниләре, туганнары, дуслары армиягә озатты. Казанда республика җыелу пунктында медицина тикшерүе узганнан соң, булачак солдатлар хәрби частьларга юл алды. Яшь солдатлар Әстерхан өлкәсендә, район шефлыгында булган частьларда хәрби бурычын үтәячәк. Быел көз Зәйдән 60ка якын егет Россия армиясе сафларын тулыландырачак. Бу көннәрдә армиягә китәчәк егетләр хәрби комиссариатта медицина тикшерүе үтә.
(«Зәй офыклары»)

Саба

17 октябрьдә районның ЗАГС бүлегендә 100 нче бала теркәлде. Күпбалалы гаилә – Гөлия һәм Фәнил Шәфигуллиннар кызларына Әминә исеме куштылар. Әминә – гаиләдә бишенче сабый. Район ЗАГС бүлеге хезмәткәрләре Шәфигуллиннарны кызлары туу вакыйгасы уңаеннан котлап, чын күңелдән аларга тигезлек, балаларын сау-сәламәт, бәхетле итеп үстерүләрен теләде. Искәртеп үтәбез: статистика бүлеге мәгълүматлары буенча, быел район буенча туучылар саны 200дән артык. Бу сан аермасы әниләрнең баланы Казан ЗАГСларында теркәүләре белән аңлатыла.
(«Саба таңнары»)

Тукай

Күптән түгел Куады авылында гомер итүче I группа инвалид, утыз алты яшьлек Рамил Тимеровның да хыялы киң күңелле кешеләр ярдәмендә тормышка ашкан. Рамил үзләренең Хуторский урамыннан агучы елга аша яңа күпер салынуын теләгән. Әнисе Фидая ханым аның бу теләген район башлыгы Фаил Камаевка җиткергән. Күперне «Тукайтеплогаз» оешмасы хезмәткәрләре төзегән. Уңайлы, куркынычсыз булсын өчен, алар төшү-күтәрелү урыннары турында да онытмаганнар. Яңа күпергә Рамил Тимеров кына түгел, аның белән бер урамда яшәүчеләр дә куана.
(«Якты юл»)

ӨМЕТЛЕ ӨЧЬЕЛЛЫК

Сәламәтлеккә игътибарны көчәйтергә, бюджет тармагында эшләүчеләрнең хезмәт хакын арттырырга, авыл халкын да онытмаска. Татарстан Дәүләт Советында узган киләсе 2024 елга һәм 2025–2026 елларның план чорына бюджет турында закон проекты уңаеннан парламент тыңлаулары вакытында әнә шундый фикерләр дә яңгырады.

tatarstan.ru

Татарстанның финанс министры Радик Гайзатуллин иң элек алдагы өч елга фаразланган бюджет керемнәренә тукталды. Аерым алганда, киләсе елда табышка салымның гомуми күләме 112,8 миллиард сум тәшкил итәр дип көтелә. Татарстанның берләштерелгән бюджетына физик затларның керемнәренә салымнан 137,5 млрд сум күләмендә акча керер дип планлаштырыла, шуның 96,4 млрд сумы – республика бюджетына. Берләштерелгән бюджетка акцизлардан 43 млрд сум өмет итәләр. Оешмаларның мөлкәтенә салымнан – 39,1 млрд, җир салымыннан – 8,4 млрд, транспортныкыннан – 6,9 млрд сум акча керер дип фаразлана. Берләштерелгән бюджетка салым булмаган керемнәр 22,4 млрд сум күләмендә булыр дип көтелә, шуларның 17,1 миллиарды республика бюджетына керәчәк.

Алдагы өч елда барлык муниципаль берәмлекләрнең бюджетлары кытлыксыз булыр дип фаразлана. Радик Гайзатуллин сүзләренә караганда, бюджетта беренче чираттагы һәм социаль әһәмияткә ия булган чыгымнарның күләме арта. Алдагы өч елда чыгымнарның дәүләт программалары буенча бүленеше дәвам итәр дип фаразлана.

– Шулай ук бюджетта – резерв фондларын формалаштыруга, капиталь чыгымнарга, илкүләм һәм төбәк проектларын гамәлгә ашыруга, бюджет оешмалары тарафыннан милек салымын һәм җир салымын түләүгә, хезмәт хакын күтәрүгә акчалар каралган. Халыктан җыелган үзара салым акчасын җәлеп итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, бюджетара трансфертларны бүлеп бирүне дәвам иттерү тәкъдим ителә, – дип ачыклык кертте Радик Гайзатуллин.

✓Гомумән алганда, киләсе елда берләштерелгән бюджетның керем һәм чыгым өлеше 451,7 миллиард сум булыр дип уйланыла.
✓2025 елда Татарстанда берләштерелгән бюджетның кереме – 458,4 миллиард сум, чыгымнар – 470,9 миллиард сум тәшкил итәр дип фаразлана.
✓2026 елда исә, фараз буенча, республикада берләштерелгән бюджетның кереме – 487,4 миллиард сум, чыгымнар 506,1 миллиард сум тәшкил итәчәк.

Республиканың төп финанс законы эчтәлеге белән танышканнан соң шактый фикер-тәкъдимнәр дә яңгырады. Татарстанның Мәҗбүри медицина иминиятләштерү фонды директоры Алсу Мифтахова фикеренчә, сәламәтлек саклау тармагына да игътибарны арттырырга кирәк. Киләсе елда бюджет кереме 79,6 миллиард сум булыр дип фаразлана. Чыгымнары да шул күләмдә булыр дип көтелә.

Татарстан Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм җитештерү сәясәте комитеты рәисе урынбасары Таһир Һадиев бүгенге катлаулы шартларда авыл халкы турында да онытмаска кирәклеген искәртте. Соңгы арада техникаларга запас частьлар хакы 1,5 тапкыр арткан. Авылларда терлек саны кими.

Арттыру дигәннән, Татарстанның профсоюз федерациясе рәисе Елена Кузьмичева бюджет тармагында эшләүчеләрнең хезмәт хакы бүгенге шартлар өчен бик аз булуын искәртте.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СУД ТҮГЕЛ

ТАТАРСТАН КОНСТИТУЦИЯ СОВЕТЫ НӘРСӘ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘЧӘК?

Республика законнарын тәртиптә тоту. Шушы максаттан чыгып, Татарстанда яңа дәүләт органы – Конституция советы оештырылды. Ул ниләр белән шөгыльләнәчәк? Әлеге структураның регламентын тәкъдим итү чарасында республиканың яңа дәүләт органы эшчәнлеге үзенчәлекләре турында сөйләделәр.

– Структура шактый яңа һәм кызыклы, – дип башлады сүзен Татарстан Конституция советы Рәисе Илгиз Гыйләҗев. – Совет эшчәнлеге конституцион законлылыкны ныгытуга юнәлдерелгән. Әмма без суд түгел. Без судтан тыш эш белән шөгыльләнәбез. Совет кабул иткән карарлар традицион суд карарларыннан шактый аерыла.

Илгиз Гыйләҗев сүзләренчә, бүген дөньяда Конституция советы идеяләрен тормышка ашыручы дәүләтләр аз калган. Алар Алжир, Казахстан, Сенегал, Франция, Шри-Ланка, Эфиопия кебек илләрдә генә бар.

– Төбәкләрдә Конституция судларын бетерү Конституция күзәтчелегендә бушлык тудырды. Ә бит моңа ихтыяҗ һәрвакыт булды һәм бар, – ди Илгиз Гыйләҗев. – Төбәк хакимияте органнары норматив актларны контрольдә тотмый, җирле үзидарә органнарының хокукый актлары турында әйтмим дә. Судка гаделлек эзләп киләләр, законлы карар алалар. Кайвакыт бу әйберләр туры килми. Үз хокуклары кысылган дип санаган гражданнардан шикаятьләр көтәбез.

Сүз уңаеннан, 100 көнлек эшчәнлек барышында бер гариза кергән инде.

Конституция советы составына гади кешеләр дә керә ала һәм бу артык мәшәкать таләп итми. Бу хакта совет әгъзасы Роман Гафаров сөйләде.

– Гаризага һәм теркәлә торган документларга карата катгый таләпләр юк. Дәүләт пошлинасын да түләргә туры килмәячәк. Кешеләргә үз хокукларын яклау өчен уңайлы шартлар тудырылырга тиеш дип санадык. Халыкка мөмкин кадәр ярдәм итәчәкбез һәм аңлатырга тырышачакбыз, – диде ул.

Моннан тыш, Советка мөрәҗәгатьләр җибәрү дә мөмкин булганча гадиләштерелгән. Аларны язма яки электрон формада юлларга мөмкин.

Конституция советы составына 35 яшьтән яшьрәк булмаган, хөкем ителмәгән, югары юридик белемле һәркем керә ала. Моннан тыш, аның юриспруденция өлкәсендә ун ел эш стажы булырга тиеш. Совет әгъзалары биш елга билгеләнә. Бер үк кеше ике сроктан артык билгеләнә алмый.

Ләйсән САФИНА

ВАТАН КАЙДАН БАШЛАНА?

tatarstan.ru

Акча һәм ватанпәрвәрлек. Татарстан Дәүләт Советының чираттагы утырышында күбрәк әнә шул хакта сөйләштеләр. Икесе ике төшенчә булса да, аларның уртак ягын да таптылар. Ул да булса, каһарманлык.

Парламент җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин рәислегендә узган утырышта «2023 елга, 2024–2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында»гы закон проектын тикшерделәр. Доклад белән Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллин чыгыш ясады. Аның сүзләренә караганда, агымдагы елда республика бюджетының керем өлеше 426,9 миллиард сум (гомумән алганда, аны 56,4 миллиард сумга арттыру күздә тотыла) тәшкил итәчәк. Чыгым өлеше – 456,6 миллиард сум (40,7 миллиард сумга арттыру фаразлана). Бюджет дефициты 15,7 миллиард сумга кимеп, 29,7 миллиард сумга тиң булачак.

– Дефицит финанслау чыганаклары белән тәэмин ителгән, – дип тә өстәде министр.

Сөйләшү барышында депутатлар махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларына төп ярдәм чараларын бюджет хисабыннан гарантияләргә кирәк, дип тә белдерде. «Хәрби хәрәкәтләр зонасында якташларыбыз үзара очрашып сөйләшәләр һәм республиканың төрле районнарында гаиләләргә ярдәм чаралары аерылуын әйтәләр. Шуңа күрә, махсус хәрби операциядә катнашучыларга төп ярдәм чаралары күрсәтүне бюджет хисабыннан тәэмин итәргә кирәк. Аерым алганда, сүз балалар бакчасына түләүсез йөрү, мәктәптә көнгә ике тапкыр бушлай ашату, гаиләне милеккә салымнан азат итү турында бара», – диделәр утырышта.

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, бюджетта тигезлекне болай да мөмкин кадәр сакларга тырышканнар.

– Бюджет балансланган. Бүгенге шартларда без каһарманлыкка тиң адым ясыйбыз, дип тә әйтергә мөмкин. Шуңа күрә закон проектын беренче һәм соңгы укылышта һәм тулаем кабул итәргә тәкъдим итәм, – диде ул.

Депутатлар бертавыштан ризалык белдерде.

Утырышта фикерләр күп әйтелгән тагын бер закон проекты турында сөйләштеләр. Депутатлар «Татарстан Республикасында гражданнарны патриотик тәрбияләү турында»гы закон проектын беренче укылышта кабул итте. Аны парламентның Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты тәкъдим итте. Документны Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе белән оештырылган эшче төркем әзерләгән. Аның составына 17 кеше, шул исәптән парламент депутатлары, Татарстан Рәисе администрациясе, профильле министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре дә кергән.

Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов билгеләп үткәнчә, яңа канун республикада патриотик тәрбиягә бердәм караш урнаштырырга мөмкинлек бирәчәк.

– Хәзерге вакытта патриотик тәрбия мәсьәләсе федераль дәрәҗәдә аерым законнар белән көйләнми, шул ук вакытта илнең күп кенә төбәкләрендә шундый ук законнар кабул ителгән һәм гамәлдә, – диде ул.

Закон проекты сессия утырышына кадәр үк комитетта сөйләшкәндә шактый фикерләр уяткан иде. Бу юлы депутатлар «Ватан кайдан башлана?» шигырен дә сөйләп күрсәтте хәтта. Тәкъдимнәр дә җитәрлек. Мәсәлән, депутатлар документта «патриотизм» төшенчәсенә тәгаен аңлатма бирелмәвен әйтте.

– Ватанпәрвәрлек, илсөярлек татар халкына һәрвакыт хас, – диде Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдулла. – Ватанпәрвәрлекне игелекле ният белән, бер максатка ирешү тирәсендә берләштерергә тиеш дип саныйм. Тарих сугышлардан гына тормый икәнен истән чыгармыйк. Халыклар һәм милләтләр төрле, алар үзара дус-тату, хезмәттәшлек итеп яшәгән. Патриотик тәрбияләү уңай мисалларга нигезләнсен иде.

Бу уңайдан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да үз фикерен әйтте.

– Әлеге закон проекты тирәсендә яңгыраган төрле фикерләрдән чыгып, без катлаулы мәсьәләне күтәрдек, дип әйтә алам, – диде ул. – Шул рәвешле, патриотик тәрбияләү белән шөгыльләнүчеләрнең дә игътибарын тагын бер кат әлеге мөһим мәсьәләгә җәлеп итәрбез дип уйлыйм. Безнe тыныч тормышта да, бүгенге кебек махсус хәрби операция барган шартларда да нәкъ менә ватанпәрвәрлек кебек фундаменталь кыйммәтләр берләштерә. Бу хакта күбрәк сөйләргә, аны үз мисалларыбызда күрсәтергә кирәк. Әлеге мәсьәләне бик вакытлы һәм бик дөрес күтәрдек дип саныйм.

Татарстан парламентында депутатлар саны кимеде. Утырышта Рөстәм Хәсәновның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителде.

– Рөстәм Хәсәнов үзе бу хакта сорап, гариза язды, – дип мәсьәләгә кагылышлы кертте Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Билгеле булганча, депутатка бәйле гауга быелның сентябрендә чыкты. Ул наркотик саклауда шикләнелә. Хәзерге вакытта Рөстәм Хәсәновка каршы җинаять эше кузгатылган. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов бу уңайдан җентекле тикшерү үткәрергә кушты. «Республика парламентаризмы тарихында мондый хәлнең булганы юк иде», – диде ул.

Рөстәм Хәсәнов 2018 елда Татарстан Дәүләт Советы депутаты итеп сайланды. Ул банкротлыкка чыккан «Реставратор» оешмасын оештыручы булып та тора. Шулай ук «Игелекле эшләр көне» хәйрия фонды директоры буларак та билгеле.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Халык кәефе

Нихәлләрдә яшәп ятасыз?

Айсылу ХӘБИБУЛЛИНА, пешекче (Әлки):
– Күптәнге хыялым тормышка ашты. Өйдә торт пешерә башладым. Аш-суга осталыгым электән бар. Гаиләбез өчен тортлар пешергәли идем. Килгән кунаклар ошатып, үзләренә дә сорый башладылар. Сарафан радиосы, диләр бит әле. Заказларым артып китте. Атнасына 10ар торт пешерәм. Шушы эшкә тотынгач, җаныма тынычлык таптым. Эшлисе генә килеп тора. Быелгы көз минем өчен бик шатлыклы булды. Инде гаилә кормам дигәндә генә, дусларым, таныштырып, ирле иттеләр. Алмаз белән бер ай гына очраштык та өйләнештек. Ике яктан да әти-әниләр исән-сау, әби-бабайлар да бар әле. Бик күңелле яшәп ятабыз.

Лилия КОРБАНОВА, иминият хезмәткәре (Минзәлә):
– Авылда тормыш гөрли. Эшнең бетәсе юк. Инде көзләргә кергәч, ял итәрбез, дигән идек. Җәен өебезне төзекләндерә башладык. Эчке ягын заманчалатырга булдык. Бар да шәһәрдәгечә булачак хәзер. «Авылларда яшәүчеләр каладагылардан кай җире белән ким?» – дидек тә тәвәккәлләдек. Бар эшне үз осталарыбыз эшли. Җиһазларны да яңартабыз. Рәхәт мәшәкать бу. Абзар тулы маллар да бар әле. Аллага шөкер, дибез. Соңгы елларда авылда терлек саны артты. Дүрт көтүлек җире бар. Кешеләр дәүләткә сөт сатып, шул акчага яши. Сөт бәясе дә күтәрелеп килә бит әле. Җәен литрын 19 сумга тапшырсак, хәзер 23 сум булды. Күп итеп тапшыргач, акчасы да әйбәт кенә чыга. Сыерларыбыз исән-сау гына булсын дип яшибез.

Рәйсә ХӘСӘНОВА, хуҗабикә (Мамадыш):
– Почтада хат ташучы булып эшли идем. Бер ай элек эшемнән китәргә туры килде. Хат ташучыга әллә ниләр йөкләделәр бит хәзер. Хезмәт хакы аз. Авылыбыз зур. Аны әйләнеп чыгарга да кирәк. Арып киттем. Әмма әле эшләр дә идем. Балаларым, Казанга күчен, диләр. Оныкларны карашырга кирәк. Бакчадагы эшләрне тәртипләп бетерәм дә шәһәргә юл тотачакмын.

Фәридә НАСЫЙБУЛЛИНА, кибетче (Апас):
– Иремне көтәм. Ул узган ел махсус хәрби операциягә киткән иде. Май аенда ялга кайтып китте. Өч баланыз бар. Алар әтиләрен бик көтә инде. Кайчан бөтенләйгә кайтыр икән, диләр. Тормышыбыз гел ирем тирәсендә генә әйләнә хәзер. Кайчак яшәргә дә онытам кебек. Әле ярый, солдат хатыннары бар. Без, берләшеп, гел хәбәрләшеп торабыз. Элек йокларга телефонны сүндереп, беренче катта калдыра торган булсак, хәзер төн буе баш очымда тора. Тормышларның шулай үзгәрәсен белмәдем.

Нурислам ИСРАФИЛОВ, машина йөртүче (Аксубай):
– Бер ай элек кинәт кенә авырып киттем. Район табиблары, бик озак тикшергәннән соң, Казанга җибәрделәр. Әлегә чиремне таба алмыйлар. Ковид галәмәте, диләр. Йөрәгемдә кимчелекләр табылды. Инде хәзер кан тамырларын тикшерергә булдылар. 1 айдан артык өйгә кайтып кергәнем юк. Хатыным белән күп итеп маллар тота идек. Аларны да бетерәсе булыр инде. Сәламәтлек бик кирәк әйбер икән. 74 яшемә җитеп, бер тапкыр да табибка барганым юк иде минем. Хәзер үкенеп тә куям. Вакытында күренәсе калган икән, дим. Эш тә кала, мал да кала – үзегезне уйлагыз.

Рәшит ГАРИПОВ, пенсионер (Тукай):
– Май аенда пенсиягә чыктым. Кодадан күреп, «Ватаным Татарстан»га язылган идем. Рәхәтләндем укып. Бик яхшы газета чыгарасыз икән. Шалтыратып, үзем әйтергә дип тора идем. Миңа сишәмбе саны бик ошый. Ятып укырлык газета бит бу. Искерми дә. Гел газета гына укып ятмыйм анысы, сатарга дип үгезләр үстерәбез. 6 үгезнең һәр ботына да хуҗа табылды инде. Кар төшкәнен көтәбез. Аннары инде терлекләрне урнаштыра башлыйбыз.

Әйтеп кенә бактым

Дуслык

Хатын-кызлар арасында бик якын кешеләрем күп. Ихластан аралашабыз, бер-беребезне якын күрәбез, ярдәм дә итешәбез. Күпләренең ирләре белән дә дустанә мөнәсәбәттә. Кайберләренеке – таныш түгел, ә кайсыларыныкы күңлләшеп тә куя икән. Үземнең хатын да вакыт-вакыт шаярткан булып шелтәләп ала:

– Дуслар гынамы соң сез, арагызда андый-мондый хәл юкмы? – ди.

– Юк!

– Белмим, – дип һаман үзенекен тукый теге, – хатын-кыз белән ир-ат арасында дуслык була аламы икән?

– Ир-егет бөтен кеше белән дә дус була ала, хәтта җәнлек-җанвар, тимер-томыр белән дә, – дип шаяртырга маташам.

Ә үзем уйлыйм. Тукта әле, дуслыкмы соң бу? Дуслык нәрсә соң әле ул?

Психологлар болай дип әйткән... Кешеләрнең төрле факторлар тәэсирендә барлыкка килгән күңел якынлыгы: психологик ярашу – омтылышлар уртаклыгы, үзара хөрмәт, ярдәмләшү, аралашуның бер дулкында булуы дуслык дип атала. Алар белән бәхәсләшеп булмый бугай. Гади генә әйткәндә, бер-береңне аңлый алу инде ул.

Әйтик, син ниндидер өлкәдә эшлисең икән, хатыныңны ничек кенә яратсаң да, аның белән үз һөнәрең буенча фикер алыша алмыйсың. Ул нинди генә гыйлем иясе булса да бу һөнәрнең нечкәлекләрен бөтен тулылыгында аңлап бетерми. Ә синең белән бергә эшләгән кеше аңлый. Фикерләр уртак, омтылышлар бер, үзара хөрмәт булганда, дустанә мөнәсәбәт барлыкка килә. Ихластан аралашасың, серләр бүлешәсең...

Әгәр кемдер сине тыңлый һәм аңлый ала икән, кирәк вакытта терәк була ала икән, бу инде – дуслык. Монда романтик хисләргә, җенси мөнәсәбәтләргә урын да калмый, алар артыкка әверелә. Һәрбер кеше үзен ишетүгә, аңлауга мохтаҗ. Мәхәббәттә бәхетлеләр дә шулай. Ә сине аңлый алган кешенең ир-атмы, хатын-кызмы икәне мөһим түгел.

Ләкин дуслык – үз урынында, мәхәббәт үз урынында кала. Гаилә – беренчел. Дуслар күп булырга мөмкин, ә гаилә берәү генә. Мәхәббәтсез гаилә – гаилә түгел.

Бу ике як та саф күңелле булган очракта шулай. Идеалда дип әйтәсем килми, үземнең дә якты дусларым җитәрлек, танышларым арасында да ир-егет белән хатын-кыз дуслыгына үрнәк булучылар күп.

Ә тормышта төрле хәлләр була. Дуслыкның бит аның мәхәббәткә әйләнеп китү мөмкинлеге дә бар. Әгәр кыз белән егет арасында шундый хәл туа икән, бик яхшы. Димәк, гаилә ныклы булачак. Мәхәббәт үзе үк – дуслыкны да эченә ала торган төшенчә бит ул, гаилә әгъзалары үзара дус булырга тиеш.

Әгәр инде гаиләле кешеләр арасындагы дуслык мәхәббәткә әйләнеп китсә... Монысы бераз хәтәррәк. Әлбәттә, ныклы гаиләләрдә андый хәл була алмыйдыр инде. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр бозылып, мәхәббәтләре сүрелгәнгә шулай килеп чыгадыр... Монда хәтта сүз әйтү дә авыр. Тик барыбер... Гаиләне җимерә торган дуслык... Сәер яңгырый, шулай бит?

Гомумән, дуслык ул – беркадәр куркыныч нәрсә. Ул төзи дә, җимерә дә ала. Кем нинди ният белән дуслаша бит. Берәүнең дә эчен ачып карап булмый. Үзара якын мөнәсәбәттәге кешеләрнең максатлары төрле булырга мөмкин. Икәүнең берсе мәхәббәтен аңлатырга кыймаган өчен генә дус булып кылана ала, мәсәлән, үз вакытын көтә. Яки икесе дә шулай. Яки кайсыныңдыр күңелендә, мәхәббәт тә түгел, ә ниндидер максатка ирешү өчен җай эзләү булырга мөмкин. Файда, табыш теләге... Монысы инде ир-ат белән хатын-кыз арасындагы дуслыкка гына кагылмый. Дуслыкның төбендә нәрсә ятканын төгәл белеп булмый. Дуслык битлеге астында теләсә нәрсә булырга мөмкин.

Шуңа күрә, мин ир-ат белән хатын-кыз арасында дуслык була ала, дип исәплим. Кем белән кем арасында туса да, ул чын дуслык булсын. Якты дуслык.

Марат КӘБИРОВ

ӨЙЛӘНҮ ҺӘМ ИДЕОЛОГИЯ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Автор җомга санына язманы гадәттә чәршәмбе иртәсендә әзерли. Бу чәршәмбедә кулдан эш төште, чөнки төн буе йоклап булмады: Фәләстыйн җирендә барган вәхшәт һәм ерткычлык йөрәккә бәрде. Сиончылар сишәмбе кичендә Газзәдәге хастаханәне бомбага тотып, йөзләгән сабыйны һәм яклаучысыз тыныч халыкны үтерде. Җитмәсә, фейклар таратып: «Фәләстыйнлылар үз балаларын үзләре үтерә», – дип шау-шу кубарып маташтылар.

Мөселман илләрендә урамнар кайнады. Автор төн буе онлайн рәвештә шулар арасында булды. Көнбатыш идеологиясе кешеләрне акылдан яздыра: вәхшилекнең төп сәбәбе шул. Газзә алдына килеп, ЛГБТ флаглары болгаган, гафу итегез, чалбарларының арткы ягына ерык ясап, төймә таккан гыйбри сугышчыларын үз акылында дип атап булмый инде. Шотланд театрында «Золушка» балетында Золушканы кара тәнле егет уйный дигән хәбәргә карагыз. Ярый, килешик: театрда артистлар да, режиссерлар да акылыннан язды, ди. Массакүләм тамашачы бар бит. Алар ничек чыдап шуны карап утыра? Британ һәм АКШ кораллы көчләренең сиончылар оештырган геноцидны тәэмин итү өчен күләмле хәрби куәтләр китерүе аңлашыла инде шуннан соң. Боларда гадәти кешелек хисләре кала алмый. Кулларына F-16 штурвалын тоткан очучыларның ваемсыз рәвештә тыныч халык өстенә фосфорлы бомбалар яудыруына шуңа күрә гаҗәпләнергә кирәкми.

Иртән, тынычлану өчен, берникадәр классик әдәбият укып алырга булдым. «Табигать балалары» дигән лирик сюжетлы матур хикәя бар бит әле. Галимҗан Ибраһимовка ияреп, егерменче гасыр башына – кешеләрнең хәзерге кебек үк акылдан язып бетмәгән чагына кайтып алдым. Хикәянең каһарманы – 21 яшьлек карт егет. Карт егет дигәнгә аптырамагыз, чөнки авылдашлары аның турында: «Хафиз бик өйләнер иде дә, аңар дигән кыз тумаган, ди, анасының карынында, ди әле...» – дип көләләр. Болай егетнең өйләнер өчен бар җире дә килгән: өч аты, ике сыеры, ун баш сарыгы бар, шулар белән йөртын алты почмаклы иткән, башка каралты-курасын яңартып килә. Моның өчен аңа һич кенә дә ипотека да, кулланучылар кредиты да алырга кирәкми. Җиң сызганып бер кыш эшли дә йорт торгыза, тагын бераз тырыша да башкасын аякка бастыра. Ул чактагы икътисад моделе белән хәзергесен чагыштырыйк. Туксанынчы еллар башында бу юллар авторының да абзарында терлекләр саны Хафизныкына якын иде. Әмма алар баетасы урынга, бөлдерделәр. Терлек тотып, мал асрап йорт салу турында хәзер дә хыяллана алмыйсың.

Бар нәрсәсе дә җитеш булгач, Хафизга кызыгучы кызлар да юк түгел, әмма егетнең үзе яраткан Әсмага өйләнәсе килә. Әсманы исә әтисе бирми: «...Сөеп алган, сөеп барган – алар бәхетсез булалар», – дип әйтә. Хафиз үзе дә өйләнер вакыты күптән җитүен аңлый: «Минем кебек ялгызлар унҗиделәре керер-кермәс өйләнә башлый: әнә миңа яшьтәш Намаҗан Гыйлаҗыйның тиздән атта йөри башларлык малае да бар инде», – ди.

Укучы сизә торгандыр: автор гаилә кору темасына сүз кузгата. Уналты-унҗиде яшьлек егетләрнең ундүрт-уналты яшьлек кызлар алуын аңлау кыен түгел. Өйләнү яшенең нормасы ул чакта якынча шундый. Кызлар турында әйтеп тормыйк, егетләр шуннан узгач, ирония объектына әвереләләр. Яхшымы бу, яманмы? Хәзер инде тыелган бер социаль челтәрдә өлкән яшьтә булган бер хәзрәт: «Минем әбием унөч яшьтә кияүгә чыгып, алты бала тапкан», – диебрәк пост язган иде. Хәзергә либераль карашлы ханымнарның берсе: «Әбиегез күпме яшәгән соң?» – дигән сорау бирде. Иртә кияүгә чыгып, күп бала табу кешене картайта, тиз үлемгә китерә дигән фикер туа. Ә хәзрәтнең әбисе 87 яшькә кадәр яшәгән...

18 октябрьдә Татарстан мәчетләрендә өйлә намазыннан соң Фәләстыйн мөселманнары өчен җәмәгать белән дога кылып, бу җирләрдә тынычлык урнашуын, кайгы-борчуларның тәмамлануын сорадылар.

Хәзерге балалар физик яктан тагын да тизрәк өлгерә. Акселерация. Өйләнү яше исә шактый югары. Һәрхәлдә, уналты яшьтә өйләнүне безнең менталитет кабул итми. Психик җитлеккәнлек бик соң килә чөнки. Белгечләр хатын-кызлар психик яктан 28–30 яшьтә, ир-егетләр тагын да соңрак – 32–34 яшьләрдә генә өлгерә дип саный. Ирләрнең гомер озынлыгы күпме әле? Мөнә шул-шул, акыл кереп, яшәп калырга да өлгермибез. Хәзерге психологлар төрек солтаны Фатихның 12 яшьтә дөньяның иң куәтле державасы белән идарә итә башлавын, 17дә өйләнүен, 20 яшьтә Константинопольне яулавын, моның өчен тарихта күрелмәгән маневр ясавын: хәрби-диңгез флотын җирдән өстерәп алып барып, Алтын мөгез култыгына төшерүен белмиләр. Шунсыз Константинопольне яуларлык булмый: шәһәр яхшы ныгытылган, бары тик диңгездән генә һәм көтмәгәндә генә бәреп кереп була. Икенче бер державаның башкаласы булган шәһәргә карап: «Я мин сине, я син мине», – дип әйткән яшь ир мәсьәләнең хәрби чишелешен аңларлык дәрәҗәдә җитлеккән була шул.

Җенси яктан 12–13 яшьләрдә үк өлгергән, әмма утызны узганчы инфантиль калган яшьләр проблемасы җәмгыятьнең авырткан урынына әверелә. Зина тарала, аңа абортлар ияреп килә яисә әтисез туган балалар саны геометрик прогрессия тәртибендә үсә. Әти булу дәрәҗәсенә үсә алмаган сакаллы сабыйлар җаваплылыктан куркып качалар чөнки. Хәзерге матбугатны алып карасаң, моның хатын-кызның төп проблемасы икәнен күрәсең. Кызлар балаларын әнигә калдырып, читкә китеп эшләп яшәргә мәҗбүр була. Гаиләне туйдырырга, баланы үстерергә кирәк бит. Кайберсе шулкадәр ияләнеп китә: әллә ничә бала табып ташлап калдыра. Проблеманы хәл итә алмаган җәмгыять моның барысын да рөхсәт итә: либераль идеологияне мәйданга чыгара. Физиология дигән нәрсә бар: кешенең җенси теләкләре канәгатьләндерелмичә кала алмый. Шулай булгач, рөхсәт итәргә туры килә. Никахсыз гына егет белән кызның бергә яшәвенә хәзер беркем дә гаҗәпләнми. Табигый кабул ителә. Хәтта өстенлек булып санала. Бик зур фаҗигаләргә китерә бу. Психика бозыла. Нормадан тайпылышлар нормага әверелгәч, ирләрнең ирләрне сөюен дә кабул итү артык авыр булмый. Психик дискомфорттан котылу өчен, алар үзләрен өстен дип санап юанырга тырыша. Һәм без җанны тетрәтә торган вәхшәт күренешләре белән торган саен ешрак очрашабыз. Алар нормага әверелә һәм барыбыз бергә зур һәлакәткә таба юл тотабыз. Кыямәтнең кече билгеләре өзелгән дисбенең сәйләннәре кебек бер-бер артлы коелып тора һәм безне зур билгеләргә таба өстери.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

СӨТ УРЫНЫНА – ИТ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«ВТ» архивыннан

Сыерсыз тормыш

Мөслим районының Мәлләтамак авылында яшәүче Гөлүсә Сәлахова әйтүенчә, соңгы елларда авылларда болай да терлек саны кими. Быел бу күренеш аеруча нык сизелгән.

– Сөт хакы да төште, икмәк тә арзан түгел. Төп сәбәп шул. Авыл зур булса да, көтүгә чыга торган маллар йөзгә дә тулмый хәзер, – диде ул. – Күпчелек кеше сыерларын көзен, кышка кергәнче бетерә. Минем күршеләр дә сыерларын сатуга куйды. Алучы гына юк әле. Сата алмасалар, иткә җибәрербез, дип торалар. Быел халык агрофирмадан салам да ала алмады. Алар да малларын бетерде. Хәзер халык өчен тырышкан хуҗалык җитәкчеләре юк инде. Кем ничек һәм кайдан таба алды, шулай юнәтте. Без үзебез печәнне сатып алдык. Малларыбыз ишле, әлегә бетерү турында уйламыйбыз. Балалар белән бергә торгач, үзебез өчен тотабыз.

Авылда сыерларны бетерүнең берданбер сәбәбе сөт хаклары төшү дип кенә әйтү дә дөреслеккә туры килеп бетмәс иде. Без алда телгә алган сәбәп болай да тырышып-тырмашып яшәгән халык өчен соңгы тамчы булды.

Теләче районының Алан авыл җирлегендә ел башында 631 мөгезле эре терлек исәпләнгән. Шуларның 203е – сыерлар. 1 октябрьгә мөгезле эре терлек саны 639га җиткән, тик сыерлар 188гә калган.

– Кимү алга таба да дәвам итәр, дип уйлыйм, – диде җирлек башлыгы Булат Хәсәнов. – Чөнки авыл картая, өлкән кешеләр малларын бетерә. Моннан тыш, терлекләрдә дә төрле авырулар чыгып тора, кысыр да калалар. Сыерларның кимү сәбәпләре әнә шулар. Бездә терлек азыгы белән проблема юк. Хуҗалык бу яктан ярдәм итә. Сөт бәяләре дә 1 сум 50 тиенгә күтәрелеп, 22 сум 50 тиен булды. Узган ел белән чагыштырганда азрак, әлбәттә. Тик кышка таба бераз күтәрелеш бар.

Кайбыч районының Чүти авылында да җәйдән башлап сыерлар саны кимүгә таба бара.

– Авылларда колхозлар бетте, терлекләргә нәрсә ашатырга соң? Безнең кооператив та сөт белән шөгыльләнүне туктатты. Чөнки сыерлар кимеде, сөт тапшыру бетте диярлек, хаклары юк, алга таба да яхшыга өметләнергә кирәкми, – диде «Йолдыз» кооперативы вәкиле Гөлназ Щукина.

Тамак тук, ләкин...

Шушы авылда яшәүче Гөлнур Хәмәтшина ире белән бергә моңа кадәр күп терлек асраганнар, тик быелдан мөгезле эре терлекләрен бетереп, ат асраугa күчкәннәр.

– Терлек асраган кешенең тамагы тук була. Без дә малларның файдасын күп күрдек. Тик аларның мәшәкате дә, эше дә шактый. Өченче ел сараебызда җиде баш терлегебез бар иде. Акрынлап кимертергә булдык, чөнки яшь бара, сәламәтлек какшый. Шуңа күрә ял итәргә булдык, инде тапкан малларның игелеген күрергә язсын. Ләкин шулай да малларны бөтенләй бетермәдек. Яхшы итеп сарайлар төзеп куйган идек, аларны ничек буш тотасың? Бүген иптәшем атлар белән генә шөгыльләнүгә күчте, сарыкларыбыз да бар. Терлекләрне бөтенләй бетерергә җыенмыйбыз, – диде Гөлнур ханым.

Буа районындагы бер кооператив башлыгы әлеге вакытта сөтне 36 сумнан кабул итүләрен әйтте. Дөрес, исемен әйтмәүне сорады.

ШӘХСИ ХУҖАЛЫКЛАРДА МӨГЕЗЛЕ ЭРЕ ТЕРЛЕКНЕҢ КИМҮ СӘБӘПЛӘРЕ

1. Сөт бәясенең арзан булуы.
2. Терлек азыгының кыйммәтләнүе.
3. Буыннар алмашу: өлкән буын картая, яшьләр мәшәкатеннән курка.
4. Кибет киштәләрендәге көндәшлек.
5. Терлек авырулары.

– Без башкаларда сөт бәясе бик нык төшкән вакытта да 26–27 сумнан киметмәдек. Шәхси хуҗалыклар, чыннан да, бик арзан бәягә тапшырды сөтне. Шул сәбәпле районда сыерларын бетерүчеләр артты. Кимү шәхси хуҗалыкларда да, фермер хуҗалыкларында да күзәтелә. Үзебезнең эшчеләр арасында да малларын бетерүчеләр бар. Без быелгы сөт чыгымнарын исәпләп чыгармыйча, аның үзкыйммәтен төгәл әйтә алмыйбыз. Узган ел ук сөтнең бер литрыннан 1–2 сум гына файда ала идек. Ә быел чыгымнар тагын да артты. Хуҗалыкларга нидер планлаштыру өчен өч елга фараз төзергә кирәк. Бездә кулланучылар саны буенча да, кадрлар мәсьәләсендә дә, республикада ачылачак комплекслар буенча да мәгълүмат булырга тиеш, – диде әңгәмәдәшебез.

Ярдәм кирәк

Әле 2019 елда гына да Татарстанның барлык төр хуҗалыкларында 1 миллионнан артык мөгезле эре терлек булган. Өч ел эчендә алар 106 меңгә кимегән. Авыл хуҗалыгы оешмаларында (шәхси хуҗалыкларны исәпкә алмыйча) терлекләр 79 меңгә кимеп, 642,5 мең башка калган.

Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, бүген Татарстанның барлык хуҗалыкларында 905798 мөгезле эре терлек бар. Аларның 322780е – сыерлар. Шәхси хуҗалыкларда – 277302 мөгезле эре терлек, шуларның 99532се – сыерлар. Ел башыннан кимү 3–5 процент чамасы тәшкил итә.

Сыерлар 22 районда кимегән. Аларның күпчелеге инвесторларга туры килә. Әйтик, Яңа Чишмә районында сыерлар ел башыннан – 1900гә, Алексеевск һәм Әлкидә – 1 меңгә якын, Теләче һәм Кайбыч районнарында 700гә кимегән. Терлек санын арттыруда Минзәлә, Кукмара, Балтач, Мамадыш, Алабуга һәм Бөгелмә районнары гына тырыша.

«Быел республикада җиде хуҗалык терлеген бетерде. Сәбәбе – малларның карт, матди-техник базаның иске булуы. Эре холдинглар да терлекләрен киметә, ләкин аларның сәбәпләре башка. Алар сөтне күбрәк бирә торган токымнарга өстенлек бирергә тырыша», – дигән иде авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек

Уртача алганда, Россиядә бер сыер елга 8,2 мең кг сөт бирә. Татарстанда – 7,3 мең кг. Шәхси хуҗалыкларда – 3,5 мең кг.

министры Марат Җәббаров игенчеләр бәйрәме алдыннан биргән бер әңгәмәсендә.

Шуңа күрә сыерлар саны кимесә дә, савып алынган сөт күләме буенча (2 млн тонна) Татарстан ил буенча беренчелекне саклый. Ә менә продуктлылык, ягъни бер сыердан савып алынган сөт күләме буенча без нибары егерменче баскычта гына торабыз. Әлегә безнең сыерлар елына уртача 7,3 мең литр сөт бирә. Максат – 7,8 меңгә җиткерү.

Бу атнада Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында да терлек саннары кимү, аерым алганда, аңа китергән сәбәпләр турында сүз кузгаттылар. Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов авыл хуҗалыгы министры урынбасары Ленар Гариповтан, сөт бәяләре төшү сәбәпле, хуҗалыкларның күпме акча югалтулары белән кызыксынды. Министрлык вәкиле хуҗалыкларның бер литрдан 7,5 сумга азрак акча алуларын әйтте.

– Бүген сөт бәяләренең күтәрелүен күрәбез, – диде Ленар Гарипов. – Атланмай һәм майсызландырылган сөткә ихтыяҗ барлыкка килде. Майсызландырылган коры сөтнең уртача хакы 135 сумнан 172 сумга кадәр күтәрелде. Хуҗалыклар тапшыра торган сөтнең уртача бәясе бүген 27 сум 82 тиен тора.

Ләкин бу – барыбер узган ел белән чагыштырганда 10 сумга кимрәк дигән сүз. Марат Әхмәтов исәпләп чыгаруынча, югалтулар якынча 15 млрд сумны тәшкил итә.

– Ашлык базары да, сөт базары да зур югалтулар кичерә. Шәхси хуҗалыкларда мал санын саклап кала алмау куркынычы бар, аларга нинди дер ярдәм чаралары турында уйларга кирәк булыр. Алар буенча нидер карарга була әле. Мондый куркыныч эре оешмаларда да бар, тик алар буенча бик сак булырга кирәк, – диде ул.

Комитет җитәкчесе урынбасары Таһир Һадиев тәкъдимнәрен дә җиткерде. Беренчедән, сөт җитештерүчеләргә бюджеттан 1 литрына 3 сум күләмендә субсидия бирүне карарга кирәк. Икенчедән, шәхси хуҗалыклардагы сыерларга ел да бирелә торган ярдәм күләмен арттырырга.

– Авылларда сыерларны кимәтү, бетерү бара. Әгәр аны бер бетерәләр икән, башка тотмаячаклар. Ә без аларны саклап калырга телибез икән инде, акча янчыгын чишәргә туры киләчәк, – диде Таһир Һадиев.

КӨЗЛЕК ТҮГЕЛ ЙӨЗЛЕК

Илдар Мөхәммәтҗанов

Узган айда пальто, куртка кебек өс киемнәре 30 процентка (!) кыйммәтләнгән. Белгечләр әнә шулай ди. Көзгә кергәч, сезонлы киемгә бәя арта инде ул, дип кул селтәргә ашыкмагыз. Әйтүләренә караганда, кием-салым бәясе, шул исәптән өс киемнәренеке дә, ел азагына кадәр үсәргә мөмкин. Өс-башны бүген үк яңартыргамы? Әллә искесе дә ярап торамы? Үзебезнең җитештерүчеләр ни хәлдә? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

Пальтоны җәен аласы

Түбән Камада яшәүче Эльмира Гарифуллина чананы – җәен, арбаны кышын әзерли. Июньдә үк үзенә аккош мамыгы тутырылган кышкы куртка алып куйган ул.

– Җәен кышкы өс киеме сатып алуыма дуслар бик гаҗәпләнде инде. Аның каравы, хәзер миңа карап: «Их, оттың!» – диләр. Исеме билгеле булган кием кибетендә ташламалар чоры башланганны көттем дә 5 мең сумга озын җылы куртка сатып алдым. Хәзер мондый өс киеменең бәясе 15–20 мең сумнан да ким түгел, – ди Эльмира Гарифуллина.

Кайда егыласымны белсәм, салам түшәр идем, диләр бит. Узган айда гына да өс киеме 30 процентка диярлек кыйммәтләнгән. «Гадел билге» дәүләт маркировкалау системасы белгечләре хәбәр итүенчә, көзнең беренче аенда пальто бәясе – 22, плащ – 34, ә куртка хакы 37 процентка арткан. Бүген көзге куртка сатып алу өчен уртача – 5500, пальтога – 9700, ә плащка 7400 сум акча кирәк, диләр. Бәяләрнең ни өчен бу кадәр югары сикерүен дә аңлатканнар. Хәер, әйтмәсләр дә билгеле. Беренчедән, доллар күтәрелде, икенчедән, логистикага, ягъни алып кайтып урнаштыруга бәйле кыенлыклар үзенекен итә. «Гадел билге» белгечләре китергән тагын бер сан: бүген илдә сатылучы барлык төр пальтоларның – 74, курткаларның – 67 һәм юка курткаларның (ветровка) 55 проценты читтән кайта. Көзге кием-салым бәясе кыйммәтләнгәч, кышкысының хакы үсәчәгенә дә шик юк. Кайбер мәгълүматларга караганда, декабрь азагына кадәр сезонлы кием тагын 20 процентка кадәр артырга мөмкин. Шуңа күрә билне ныграк кысып буарга туры килмәгәе.

Вьетнам базарында кием-салым бәяләре (сумнарда)

Ирләргә көзге куртка	4500
Ирләргә кышкы куртка	5500
Хатын-кызларга көзге куртка	3300
Хатын-кызларга кышкы озын куртка	6000
Балаларга кышкы куртка	4500
Хатын-кызларга баш киеме	700
Ирләргә кышкы аяк киеме	3200
Балаларга пирчәткә	350

«Бәя артканны көтеп ятмагыз»

Кибеттә бәяләрнең гел артып торуы аңлашыла кебек: сыйфатлы товар арзан тормас. Соңгы арада интернет-кибетләрне үз итүчеләр дә андагы бәяләрнең кыйммәт булуыннан зарлана башлады. Онлайн сәүдә алып баручылар да акчаның тәмен сизгән, күрәсең. Ә базар нихәл? Бу сорауга җавап эзләп, халык телендә «Вьетнам базары» дип йөртелүче урынга юл тоттык.

Базар элеккечә эшли. Сатучылар күп, киштәләр тулы, тик сатып алучылар гына әллә ни күренми.

– Пандемиядән бирле сатып алучылар шактый кимеде, – ди базарда унбиш елдан артык сатучы Гөлфания Шәяхмәтова. – Һаман да интернет-кибетләрдән чыгып китә алмыйлар әле *(көлә)*. Базарга күбрәк өлкән яшьтәгеләр һәм балалы гаиләләр йөри. Беренчеләре интернеттагы товарның сыйфатына ышанмаса, икенчеләренә кием-салымны киеп карарга кирәк. Узган ел белән чагыштырганда бәяләр артты. Шулай булмый соң, былтыр доллар 60 сум торса, быел 100 сум бит. Ел башыннан бирле чит илдән товар төялгән контейнер кайтарту – ике, ә дөнья күләмендәге хәлләр башланганнан бирле биш-алты тапкыр кыйммәтләнде. Бер капчык товарның юл хакы 1 мең сумга төшә. Шуңа күрә бәяләр артканга әллә ни аптырыйсы юк, минемчә. Бу бездән тормый. Өске киемнәр генә түгел, барысы да кыйммәтләнә. Футболка белән чагыштырганда, шул ук пальто кыйммәтрәк тора. Шуңа күрә аның бәясе арту да кесәгә күбрәк суга. Соңгы ике елда, мәсәлән, минем хезмәт хакым бер тиенгә дә артмады. Тик сатып алучыны бу кызыксындырмый. «Кыйммәт сатасыз», – дип зарлана гына беләләр.

Алинә Гатауллина базарга өч яшьлек кызына кышкы куртка алырга дип килгән.

– Балалар гел үсә. Шуңа күрә бәяләр артса да, кием-салымны гел яңартырга туры килә, – ди ул. – Интернеттан заказ бирсәң, чалбары һәм курткасы булган сыйфатлы комплект 5–7 мең сум чамасына төшә. Базарда очсызракка да табарга мөмкин. Үзебезнең җитештерүчеләрнеке арзанрак. Базарга еш йөрибез. Әйберне тотып карап алуга берни җитми. Ә кибеттә сайлау мөмкинлеге аз хәзер.

Базарда кышкы киемнәр сатуга чыга башлаган гына әле.

«Иске яңадан саклый»

Регина ӘЮПОВА, стилист:

– Заманча булып күренү өчен, баштанаяк яңа кием-салым сатып алу мәҗбүри түгел. Бу көздә һәм кышта минимализм модада булачак. Өс киеме гади һәм тыйнак булырга тиеш. Ак, кара, коңгырт, ком төсе, ачык соры төстәге кием-салымга өстенлек бирегез. Зәңгәр, яшел төсләр дә калачак. Итәкләрнең миди озынлыктагылары модада. Алар ярымкояш яки плиссе булырга да мөмкин. Мамык тукымадан тегелгән база күлмәкләре актуаль булачак. Ирләр стилендәге чалбарлар һәм чалбарлы костюмнар да кала. Джинс чалбарның гап-гади туры балаклысына өстенлек бирегез. Оверсайз-свитерларны итәк белән дә, чалбар белән дә кияргә була. Аңлашылганча, болар барысы да – искерми торган киемнәр. Бу көзнең тагын бер кәттә киеме – кара пальто. Ул күбегездә бардыр да инде. Иң мөһиме – сыйфатлы кием сатып алырга киңәш итәбез. Мода әйләнә дә кайта ул.

– Кышка дигән товар кайткан, капчыкта үз чиратын көтә, иң элек көзгесен сатып бетерергә кирәк, – ди аяк киемнәре сатучы егет. – Кайбер кышкы модельләрне генә киштәгә чыгардык. Аларны сораучылар күп түгел әле. Атна азагында һава температурасы нульдән түбән булачак, диләр. Менә шуннан соң сәүдә башланачак. Хәзер сатып алсагыз, арзанрак, көннәр суыткач, кышкы аяк киемнәре 500–1000 сумга кыйммәтләнәчәк. Бәя артканны көтеп ятмагыз.

Үзебезнеке җылырак

Республика җитештерүчеләре дә халыкны кием-салым белән тәэмин итәргә әзер. Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, былтыр республикада 400гә якын җиңел сәнәгать предприятиесе теркәлгән.

– Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бәяләр артты, әмма ул дәрәҗәдә үк сизелерлек түгел, – ди «Кукмара тегү фабрикасы» генераль директоры Руслан Голов. – Балалар, хатын-кызлар һәм ир-атлар өчен өс киемнәре тегәбез. Безнең продукциягә ихтыяҗ зур һәм ул һәрвакыт тотрыклы. Бигрәк тә, көзге-кышкы чорда. Бездә җитештерелгән продукциянең сыйфаты чит илнекеннән бер дә калышмый. Бәя арту исә иң беренче чиратта доллар курсына бәйле. Тукыма, фурнитура да кыйммәтләнде. Кирәкле чималны күбрәк Кытай һәм Кореядан кайтартабыз. Без вакыт белән бергә атларга тырышабыз. Яңа модельләр чыгарганда, сатып алучыларның фикеренә дә колак салабыз. Безнең продукция башкаларныкына караганда җылырак та әле. Чөнки кышкы киемнәрдәге җылыткыч тукыманы үзебездә үк җитештерәбез.

Спорт киемнәре тегү белән шөгыльләнүче «IDA PROSPORT» компаниясен оештыручы Сәфинә Сөләйманова да үзебезнең продукция арзанрак та, сыйфатлырак та дигән фикердә.

– Чит ил брендларының китүе безнең өчен үсеш ноктасына әверелде. Дөрес, чимал сатып алуга бәйле кайбер кыенлыклар туды. Мәсәлән, спорт курткалары өчен тукыманы Италия һәм Испаниядән сатып ала идек. Хәзер аларны Төркия һәм Кытай фабрикаларында җитештерелгәннәренә алмаштырдык. Без шул ук киемнәрне тегәбез, әмма хәзер аларның сыйфаты яхшырды. Баштарак спорт һәм өс киемнәре тегүчеләр буларак танылдык. Мәсәлән, «Ак барс» хоккей командасы өчен киемнәр тегәбез. Хәзер кием-салымга ихтыяҗ зур булуын күреп, товар төрләрен арттырдык. Яшьләр таләпләренә туры китереп, спорт костюмнары, озын футболка, кепкалар тегәбез, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Ул арада кием-салымны ремонтлау белән шөгыльләнүче ательеларда эшнең кызган чагы.

– Халык шкафта яткан җылы киемнәрен чыгара башлады. Бу арада заказлар күп. Былтыр кигән куртканың тимер төймәләрен яңартуны сорап мөрәҗәгать итәләр, пальто-курткаларны кыскартыралар. Соңгысы, мәсәлән, 800 сумнан башлана. Аның каравы иске кием яңарып китә, – дип сөйләде башкаладагы ательеларның берсендә эшләүче Резидә Миңнуллина.

Бу да – заманага яраклашуның бер билгесе инде. Хәзерге вакытта юрганны аякка карап аласы.

Эльвира ВӘЛИЕВА

27 октябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Эльвира ВӘЛИЕВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Әбине котламыйлармыни?

Күптән түгел генә Арча районының Шура авылында яшәүче әниебез, әбиебез Рауза Ганиева 90 яшен тутырды. Интернеттан күреп, башкалардан ишетеп белүебезчә, өлкән яшьтәге кешеләрне район администрациясеннән вәкил яки авыл җирлеге башлыгы кереп котлау гадәте бар. Тик, ни сәбәпледер, безнең әбине кереп котлаучы булмады. Өлкәннәргә күп тә кирәкми югыйсә. Бер җылы сүз һәм игътибар да җитә. Арча районында юбилее булган барлык кешеләрне дә котламыйлар микән әллә?

БАЛАЛАРЫ ҺӘМ ОНЫКЛАРЫ.
Арча районы Шура авылы

Арча районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Эльвира Вафина:
– Без 1931 елдан соң туган тыл хезмәтчәннәрен һәм сугыш ветераннарын исемлек буенча котлыйбыз. Гадәттә аны миңа районның социаль яклау бүлеге төзеп кертә. Әлеге исемлектә Рауза апа юк иде. Кайвакыт, чыннан да, бик нык игътибар көтүче өлкәннәребез була. Балалары, туганнары алдан кисәтеп куйган очракта, я үзем, я җирлек башлыгы кереп, котлап чыккан чаклар да була. Рауза апаны да игътибарсыз калдырмабыз.

Редакциядән. Без Эльвира Вафина белән сөйләшкән көнне үк Рауза апа Ганиеваны Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Әгъзам Гайфуллин котлап чыкты. Үтенечебезне игътибарсыз калдырмавыгыз өчен зур рәхмәт!

Җылы бирүне ник сузалар?

Шәһәрләрдә торбаларга җылыны ник суыклар башлануга ук бирмиләр икән? Сентябрьдә дә салкыннар булды бит. Эшләр буенча сентябрь ахырында башкалага барырга туры килгән иде. Салкын тигезеп кайттым. Ни өчен җылы җибәрергә октябрьне көтәргә кирәк?

Саимә СӘЛАХОВА.
Чирмешән районы
Кара Чишмә авылы

Казан мэриясенең матбугат хезмәте:
– Җылылык бирү сезоны төгәл даталарга бәйле түгел. Аны һаваның уртача температурасы биш көн дәвамында +8 градус торган очракта бирәләр. Казанда җылылык – 5 октябрьдә, ә кайбер социаль учреждениеләрдә 14 сентябрьдә үк бирелде. Әлеге вакытта җылылык шәһәрнең барлык 5523 күпфатирлы йортына һәм 852 социаль объектына да җибәрелде.

Дарулар бушлай түгелме?

Минем колакларым начар ишетә, үпкәмдә проблемалар бар. Хастаханәгә ятарга кергән очракта, барлык даруларны даруханәдән сатып алырга кирәк. Мин социаль пакеттан баш тартмадым бит. Ни өчен даруларны һәрвакыт үземә сатып алырга туры килә? Элек минем диагноз белән шифаханәләрдә ял итү өчен юллама бирәләр иде. Хәзер анысы да юк. Колак аппараты да бирмиләр. Социаль пакеттан баш тартмаган кешеләргә дарулар бушлай бирелмимени?

РИНАТ.
Биектау

Россия Социаль фондының Татарстандагы бүлеге идарәсенең матбугат үзәге:
– Әгәр социаль пакеттан баш тартмаган икән, Сәламәтлек саклау министрлыгыннан бушлай бирелә торган дарулар исемлеген белешергә киңәш итәбез.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат үзәге:
– Социаль хезмәтләрдән аерым бер категория кешеләр генә файдалана ала. Гражданин социаль пакеттан баш тартмаган очракта, дәүләт аларны бушлай дарулар белән тәэмин итәргә тиеш. Дарулар исемлеге белән рәсми сайтта (minzdrav.tatarstan.ru) танышырга мөмкин. Кызганыч, авыруның исем һәм фамилиясен, адресын һәм диагнозларын белми торып, төгәл җавап биреп булмый. Әгәр нинди дер тәртип бозу очраклары бар икән, министрлыкның Интернет-кабул итү хезмәтенә мөрәҗәгать итәргә яки 8 (843) 558-03-03 телефоны буенча контакт-үзәккә шалтыратырга мөмкин.

Редакциядән. Кызганыч, Ринат абый үзе турында тулы мәгълүматлар калдырмады. Әгәр безнең җаваптан соң да сорауларыгыз калса, тагын бер тапкыр редакциягә шалтыратуыгызны сорыйбыз.

Вакытында түләмәсәң, ни була?

Билгеле бер сәбәпләр аркасында, улым белән киявем салымнарын вакытында түли алмаслар шикелле. Салымны вакытында түли алмауның нинди куркынычы бар?

Гөлүсә ИБРАҺИМОВА.
Кайбыч

Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча 5 нче районара инспекциясенең бүлек җитәкчесе Мөнир Шәйдуллин:
– 2 декабрьдән пеня исәпләнә башлый. Бер атнадан түләмәүчеләр исемлеген билгелибез һәм судка мөрәҗәгать итәбез. Суд карары чыкканнан соң, суд приставлары эшкә керешә. Алар милеккә арест салырга мөмкин, башка чикләү чараларын куллана ала. Салым түләмәүчеләрне ЮХИДИ хезмәткәрләре дә ачыкларга мөмкин. Бу очракта автомобильгә арест салынырга мөмкин. Салым буенча әҗәте булган кешене чит илгә чыгармыйлар. Шундый күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен, салымнарны вакытында түләргә, әҗәтләр юкмы, дип белешергә кирәк. Еш кына пайчылар: «Җирдән файдаланмыйм, салымны мин түләргә тиеш түгел», – дип, бурычлы булып кала. Җир кем исемендә – салымны шул түли.

Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде

Илдар Мөхәммәтҗанов

Укучы сүзе

РИМАН ГЫЙЛЕМХАНОВНЫҢ «НИГӘ ГЕНӘ ИКӘН?» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Элеккеге кебек күңелебез киң, ризыгыбыз мул. Килгән кунакка – ачык йөз, ипи һәм тоз. Ковид чорында гына кунакларга йөреш булмады, куркытып алды бераз. Олыгайгач, гел өйдән дә чыгып йөрисе килми икән. Ярый әле яшьләребез туганлык, дуслык җепләрен өзмиләр. Матур итеп табын корып җыелалар.

Зөһрә МУЛЛАХМӘТОВА

***

Кемдә ничектер, әмма бездән кеше өзелми. Я төянеп, үзебез чыгып китәбез. Хәзинәдә бары белән кунак итәбез. Бәрәңгене дә күмәкләшеп алдык. Үзе бер күңелле булды. Әлхәмдүлилләһ шөкер.

Гөлгенә ГЫЙНИЯТОВА

ГӨЛГЕНӘ ШИҺАПОВАНЫҢ «КАДЕРЕН БЕЛМӘГӘННӘР» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Чын әти кеше икәнсез, ә иң авыр вакытта балаларны интернатка бирергә киңәш биргән «туган»нарны берничек тә туган дип атап булмый, алар белән араларны өзү хәерлерәк. Балаларыгызның игелеген күреп, озын-озак яшәргә насыйп булсын сезгә. Әгәр «күке ана» кабат кайтып гафу сораса, кертмәгез, гафу итмәгез, үзегезнең дәрәҗәгезне төшермәгез. Картайгач, беркемгә дә кирәге калмагач, кайтачак әле ул.

Тәнзилә МИҢНЕБАЕВА

ЗӨҺРӘ САДЫЙКОВАНЫҢ «КАУРЫЙЛЫ КАГЫЙДӘ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Мең казны сугым урынына ничек ташып бетермәк кирәк? Авыл кешеләреннән ничек көләргә белмиләр инде...

Илгиз САФИН

***

Мондый юләрлекне кем уйлап тапты икән? Районгдагы җаваплы кешеләргә бушлай акча эшләргә җай чыгардылар. Мескен авыл агасына кош-кортны чалдырыр өчен районга машина яллап барырга кирәк, аннан алып кайтасы бар. Кайткач, сатар өчен тамга суктырасы... Үстергәннең 60 проценты да керми бит кесәгә. Бик начар әле бу.

Рафиз НИЗАМИЕВ

***

Кош-корт асрамасыннар өчен чыгарылган закон. Фермаларны бетерәләр, тавыкларны грипп дип яндыралар, каз суйдырмыйлар. Аның каравы корт үрчетәләр. Шул рәвешле ясалма ачлык ясыйлар, ахры. Хәзер законнар бер дә халык яклы түгел.

Фәния ВАҺАПОВА-ИЗМАЙЛОВА

Фикер

Газетаның 29 сентябрь санында җеннәр турында язган идегез. Мин 90 яшемә җитеп тә, бу турыдагы уйларны башыма да китергәнем юк. Психик тайпылышлары булган кешеләр, бәлки, ышанадыр да инде. Андый язмаларны укып, чынлап та авыруга сабышырга мөмкин бит. Кеше җанына җен кереп изләшүенә ышанмыйм. Мин озын гомер кичердем, төрле урыннарда эшләдем, көнләшүчеләр дә булгандыр, тик берсеннән дә зыян күрмәдем. Башкалар да бу турыдагы уйларны читкә куеп, Аллаһка ышанып, матур гомер кичерсә иде.

Саимә СӘЛАХОВА.
Чирмешән районы Кара Чишмә авылы

23 октябрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «Кайда син?» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем…» 12+
12.00, 22.10 «Департамент» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.00 «Исчезнувшая» (Россия, 2017) 16+
00.00 «Соотечественники» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Путь» 16+
01.05 «Нәсыйхәт» 16+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.10, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Туган авылым» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «Бизон: дело манекенщицы» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Драгоценные истории» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Летописи конца времен» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+

РОССИЯ 1
05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ЗЕРКАЛО ЛЖИ» 16+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 21.30, 00.30 Все на Матч!
10.05, 12.35, 03.05 Специальный репортаж 12+
10.25 «Кто кого?» 12+
11.25, 22.15 Футбол. МИР РПЛ. Обзор тура 6+
13.00 «Есть тема!»
15.00 «География спорта. Химки» 12+
15.30 «Громко»
16.25 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Акрон» (Тольятти) – «Шинник» (Ярославль)
18.30 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» (Нижнекамск) – «Трактор» (Челябинск)
23.25 Смешанные единоборства. One FC 16+
01.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Самара» – УНИКС (Казань) 6+
03.00 Новости 0+
03.25 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Белогорье» (Белгород) – «Югра-Самотлор» (Нижневартовск) 6+
05.30 «Магия большого спорта» 12+

НТВ
04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
22.15 «БАЛАБОЛ» 16+
00.55 «ДЕЛО ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30, 05.45 «6 кадров» 16+
06.40, 05.50 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.40 «Давай разведёмся!» 16+
08.40 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.10 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.20 «Порча» 16+
12.55, 01.15 «Знахарка» 16+
13.30, 01.40 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40, 02.30 «ЛЮБОВЬ ПО КОНТРАКТУ» 16+
19.00 «НЕВОЗМОЖНОЕ ПРОЩЕНИЕ» 16+

ЗВЕЗДА
04.35 «НЕ ХЛЕБОМ ЕДИНЫМ» 16+
07.00 «Сегодня утром». 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 13.25, 01.00 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА» 12+
14.15, 19.55 «По горячим следам» 16+
14.35, 15.05, 17.15 «СМЕРШ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «СВО: компоненты силы» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ДЕРЗОСТЬ» 12+
03.15 «Неизвестная война. Великая Отечественная» 16+
04.05 «Перелом. Хроника Победы» 16+

24 октябрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.15, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Синең кузләр» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15, 00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 15.45 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «Департамент» 16+
13.00, 01.05 «Родная земля» 12+
13.30 «Казаннан – Казанга» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.15 «Синең кузләр» 16+
17.15 «Заман көзгесе» 6+
17.45 «Таяну ноктасы» 6+
19.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Авангард» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «Исчезнувшая» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.40 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Сула!» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 04.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.15. 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «Бизон: дело манекенщицы» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обман веществ» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Россия и Запад на качелях истории» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+

РОССИЯ 1
05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ЗЕРКАЛО ЛЖИ» 16+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 18.30 Новости
07.05, 15.30, 18.35, 00.00 Все на Матч!
10.05, 12.35, 03.05 Специальный репортаж 12+
10.25 «Кто кого?» 12+
11.25 «Человек футбольной породы» 12+
13.00 «Есть тема!»
15.00 «Что за спорт?» 12+
16.25 Смешанные единоборства. UFC. Ислам Махачев против Александра Волкановски 16+
19.30 Футбол. Лига чемпионов. «Галатасарай» (Турция) – «Бавария» (Германия)
21.45 Футбол. Лига чемпионов. «Севилья» (Испания) – «Арсенал» (Англия)
01.00 Футбол. Лига чемпионов. «Бенфика» (Португалия) – «Реал Сосьедад» (Испания) 6+
03.00 Новости 0+
03.25 Велоспорт. Трек. Лига чемпионов 0+
05.30 «География спорта. Химки» 12+

НТВ
04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
22.15 «БАЛАБОЛ» 16+
00.55 «ДЕЛО ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30, 05.55 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.40 «Давай разведёмся!» 16+
08.40 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.25 «Порча» 16+
12.45, 01.15 «Знахарка» 16+
13.20, 01.40 «Верну любимого» 16+
13.55, 02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «Твой Домашний доктор» 16+
14.45, 02.30 ПЯТЬ ЛЕТ СПУСТЯ 16+
19.00 «ТЫ В МОЁМ СЕРДЦЕ» 16+
05.35 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА
04.30 «СМЕРШ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.55 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА» 12+
12.25 «Специальный репортаж» 16+
13.40, 19.55 «По горячим следам» 16+
13.55, 15.05, 17.15 «КРАПОВЫЙ БЕРЕТ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «СВО: компоненты силы» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «СЛЕДСТВИЕМ УСТАНОВЛЕНО» 12+
02.05 «ДЕВУШКА С ХАРАКТЕРОМ» 12+
03.30 «Перелом. Хроника Победы» 16+
03.55 «КРАПОВЫЙ БЕРЕТ» 16+

РФ КОРАЛЛЫ КӨЧЛӘРЕНДӘ КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮ

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНУ, ДӘВАЛАНУ һӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ һӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ һӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ һӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР һӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

УЙЛАП БАС

pinterest.com

Җир шарында яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы яссытабанлылыктан интегә. Шуларның күпчелеген хатын-кызлар тәшкил итә. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматлары шул хакта сөйли. Ни гаҗәп, халык телендә «аю табаны» дип йөртелгән әлеге кимчелектән интегүчеләрнең нибары 3 процентында гына ул тумыштан килә икән. Калганнарында ул яши-яши пәйда булган. Яссытабанлылык ни сәбәпле барлыкка килә? Ул дәвалауга бирешәме?

Ортопед-травматолог Ринат МУЛЮКОВ шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Яссытабанлылык нидән гыйбарәт?

– Яссытабанлылык – табанның формасы үзгәрү. Ул табанның ян-яклары аска таба төшеп торудан гыйбарәт. Яссытабанлылык аркылыга да, буйга да була ала. Аркылыга булганда, табанның аркылы өлеше тыгызлана. Аның алгы өлеше табан сөягенең очларына таяна. Сөякләр җилләткеч кебек җәелгән була. Шуңа күрә табанның озынлыгы да кыскара. Яссытабанлылык буйга булганда, табанның буйга таба урнашкан өлеше тыгызлана. Андый чакта табан астының бөтен өслеге диярлек идәнгә тия. Табанның озынлыгы исә, киресенчә, арта.

:: Табандагы мондый кимчелек ни сәбәпле пәйда була?

– Кеше туганда ук яссы табанлы булып туарга мөмкин. Ул имгәнгән, җәрәхәтләнгәннән соң да пәйда була ала. Табан асты мускуллары параличланган очракта, сөяк авыруы (рахит) вакытында да еш кына яссытабанлылык күзәтелә. Бу табанның мускул-бәйләү аппараты үзенә төшкән авырлыкны күтәрә алмаганда килеп чыгарга мөмкин. Статик яссытабанлылык дип атала бу. Ул хәзер бигрәк тә еш (80 процент очракта) очрый. Ул, нигездә, балтыр, табан буыннарының зәгыйфь булуы аркасында барлыкка килә. Моңа артык авырлык, көн дәвамында аягөсте яки, киресенчә, утырып эшләү дә сәбәпче булырга мөмкин.

:: Яссытабанлылыкны үзлегеңнән генә ачыклап буламы? Моның өчен нинди билгеләргә игътибар итәргә кирәк?

– Була. Моның өчен табан эзенә игътибар итәргә кирәк. Юеш аяк белән идәнгә яки берәр әйбер сибелгән ак кәгазьгә басканда да яхшы күренә ул. Әгәр табан тулысынча идәнгә басып торса, кешедә яссытабанлылык дигән сүз. Мондый кимчелек булмаганда, табан эзе өлешчә генә төшә.

:: Яссытабанлылык дәвалауга бирешәме?

– Аны һичшиксез дәваларга киңәш ителә. Моның өчен иң беренче чиратта аяк киеменә индивидуаль рәвештә ясалган ортопедик олтырак алырга кирәк. Аякларга, бигрәк тә балтыр өлешенә массаж ясау да ярдәм итә. Яссытабанлылык вакытында махсус физик күнегүләрнең дә шифасы зур. Гәүдә авырлыгын да һәрчак контрольдә тоту зарур. Таш өстендә яланаяк йөрү дә табанны дәвалаганда нык ярдәм итә. Андый чакта аяк табаннары ярдәмендә теге яки бу әйберне, мәсәлән, каләмне бер урыннан икенчесенә күчереп «уйнарга» да киңәш ителә. Буш вакытта аяк очларында, аякларны чиратлаштырып, бер эз буенча барып, гади генә күнегүләр дә ясарга мөмкин.

:: Табан астындагы мондый үзгәреш, иң беренче чиратта, кемнәргә яный?

– Көн дәвамында 7–8 сәгать буе аягөсте басып эшләгән кешеләр, шул ук чәч кисүче, сатучы, массаж ясаучылар арасында бу чир күбрәк. Яшь ягыннан ул беркемне дә аямый. Яссытабанлылык бүген олысында да, кечесендә дә очрый. Ул никадәр иртәрәк ачыкланса, дәвалауга да шулкадәр яхшырак бирешә. Әйтик, балага 4–5 яшь тулгач, яссытабанлылыкны курыкмыйча дәвалый башларга мөмкин. Яссытабанлылык уңайсыз, дөрес сайланмаган аяк киеме аркасында пәйда булырга мөмкин. Биек үкчәле туфлидән йөрергә яраткан гүзәл затларга да яный ул куркыныч. Бөтен гәүдә авырлыгы табанның алгы өлешенә төшкәнлектән, аркылы яссытабанлылык килеп чыгу куркынычы бермә-бер арта. Ул нәселдән дә күчә ала.

:: Яссытабанлы кешегә спорт белән шөгыльләнергә ярыймы?

– Беренче һәм икенче дәрәҗәдәге яссытабанлылык вакытында спорт белән шөгыльләнергә ярый. Иң мөһиме – күнегүләр дөрес сайланган, аякта – ортопедик олтыраклы уңайлы аяк киеме булырга тиеш. Болар бар да тәҗрибәле тренер белән киңәшләшеп эшләнергә тиеш.

ЯССЫТАБАНЛЫЛЫК БУЛМАСЫН, ДИСӘҢ

✓Моның өчен, иң беренче чиратта, үз размерыңа туры килгән, уңайлы аяк киеменнән йөрергә кирәк. Хатын-кызларга үкчәсе 4–5 сантиметрдан да биегрәк булмаган туфли кияргә киңәш ителә.

✓Дөрес итеп, туры атлап йөрү дә мөһим.

✓Табан асты сау-сәламәт булсын өчен, җәен чирәмдә, ташта яланаяк йөрергә тырышыгыз.

✓Йөзү, аякларга массаж ясау да яссытабанлылыкны кисәтә.

✓Күп итеп җәяү йөргән, озак вакыт аягүрә басып торганнан соң аякларны ял иттерергә дә онытмагыз.

✓Яссытабанлылыкның беренче билгеләре күренүгә үк, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Ябык кешедә аю табаны булмый, диләр. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Юк, бу – уйдырма. Яссытабанлылык авырлыкка карап тормый. Ул ябык кешеләр арасында да, тулы гәүдәлеләрдә дә бер үк дәрәҗәдә очрый. Дөрес, соңгыларында бу куркыныч күбрәк яный. Ник дигәндә, әйткәнемчә, яссытабанлылык еш кына артык авырлык аркасында да пәйда була.

Беләсезме?

Яман шештән саклый

Шампиньон гөмбәсе яман чирне кисәтә. Табиб-диетолог Елена Соломатина «Москва 24» каналындагы тапшыруда шул хакта сөйләгән. Моннан тыш әлеге гөмбә атеросклероздан да ярдәм итә икән. «Шампиньонда клетчатка күп. Ул исә, үз чиратында, организмнан артык шикәрне, холестеринны чыгарырга ярдәм итә», – ди табиб. Шампиньон селен, бакыр, В төркеме витаминнарына да бай. «Организмга селен җитмәсә, калкансыман биздә проблемалар килеп чыга, аның эшчәнлеге акрыная һәм гипотиреоз башлана. Бакыр тән өчен җавап бирә. В төркемендәге витаминнар метаболизм процессларын яхшырта», – ди табиб.

Йөрәккә дә файдалы

Мельбурндагы Дикин университеты галимнәре, даими рәвештә С витамины куллану 2 нче типтагы шикәр чиренә каршы көрәшергә ярдәм итә, дип ышандыра. Әлеге витамин кандагы шикәр күләмен киметә икән. Көнгә ике тапкыр 500әр мг С витамины куллану канда шикәр күләмен сизелерлек төшерергә ярдәм итә, ди галимнәр. Әлеге витамин югары кан басымын төшерә, йөрәк һәм кан тамырлары авыруларын да дәвалый.

Миләшнең шифасы

Күз күнә уттай янып утырган миләшнең шифасы бик зур.

Миләш согы. Аны ясау өчен 400 г миләшне изеп, аңа 2 литр кайнаган су һәм берәз шикәр комы салырга, дүрт сәгатьтән соң болгатып, сөзеп эчәргә кирәк. Эч катканда берничә атна буена көнгә өч тапкыр 70–100 грамм шундый сок эчәргә киңәш ителә.

Азканлылыктан. Ике аш кашыгы кызыл миләш җимешен ике стакан кайнар суга салып, бер сәгать тәнәткәч сөзәргә. Шуны көн буена өч-дүрт тапкыр аз-азлап эчәргә кирәк.

Үт куыгы ялкынсынган (холецистит) кешеләр дә миләш согының файдасын күрә. Халык медицинасында ул кан басымын нормада тоту өчен дә кулланыла. Моннан тыш кызыл миләшне изеп, шикәр комы һәм кайнар су белән болгатып, йоклар алдыннан эчү дә файдалы.

Миләшне кан әйләнеше системасы бозылганда, сидек юллары ялкынсынганда, ташлар булганда файдаланалар. Аны чәйгә кушып эчәргә яки төнәтмәсен ясарга кирәк. Миләш суын ясау өчен, стакан ярым суга бер кашык изелгән җимешен салып пешерергә. Шуны көнгә 2–3 мәртәбә яртышар стакан эчәргә. Икенче ысул: 2 кг миләшне юып, 2 литр суга салырга һәм йомшарганчы пешерергә. Иләк аша уып сыгарга да, пыяла банкаларга салып, 15 минут пастеризацияләргә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Белеп тор!

Ялт иттерә

Өйдә булган гап-гади әйберләр кайчак кыйммәтле чараларны да алыштырырга мөмкин. Мәсәлән, өй җиһазлары, шкаф, линолеум, плитка, батарея һәм көнкүреш техникаларын чистартырга, тапларны да түбәндәге катнашма белән бетерергә була.
1,5 л җылы суга ике аш кашыгы сода, ике аш кашыгы серкә эремәсе, бер аш кашыгы лимон кислотасы салып болгатырга. Әлеге эремәдә губканы чылатып, таплы, пычранган әйберләрне сөртергә. Бик нык каткан урыннарга пульверизатор белән сиптереп, бераз тотканнан соң сөртеп алырга була.

Психология

Төсе кәеф күтәрә

Алтын көздән соң күпләр бик үк өнәп бетерми торган чор башланды. Әмма табигатьнең төссез мизгеленә кергәннән соң, төсле киемнәргә өстенлек биреп, кәефне күтәреп җибәрергә була.
Салкыннарда иң кирәкле киемнәрнең берсе – водолазка. Аны сайлаганда бөтен киемгә дә бара дип, база төсләргә генә түгел, ә янып торган, ачык төсләргә дә игътибар бирсәгез, оттырмассыз. Мәсәлән, фуксия төсе үзеңнең бәяңне күтәреп җибәрә, кәефне күтәрә, энергия һәм позитивлыкны аңлата. Ә шафталу төсенә тартым ачык ал төс гармония, нәфислек, серлелеке белдереп, тирә-юнегездәгеләр тарафыннан да бик җылы кабул ителер.

Матур бул!

Бетчәдән коткара

Әлеге битлек бетчәдән интегүчеләр өчен файдалы.
Коры чүпрәгә су салып, бик үк сыек булмаган «ботка» ясагыз. Шуны сөртеп, 15–20 минут чамасы хәрәкәтләнми генә ятып торыгыз. Җылы су белән юып алыгыз. Әлеге битлек, әлбәттә, битне тарттырган сыман итәр, әмма нәтиҗәсе бер кулланыуда ук күренәчәк: бетчәләр кибә, тире тигезләнә, сәламәт төс керә. Аны ике атнага бер ясарга була. Бит тиресенә битлектән соң үзегезгә туры килә торган крем сөртеп куярга була.

Гөлгә дә тимер кирәк

Илдар Мөхәммәтҗанов

Тәтеш районының Байраш авылында яшәүче Алсинә Сафиуллинаның бакчасы яздан көзгә кадәр шау чәчәктә. Сезон лаләләрдән башланып, дәлияләр белән тәмамлана. Шулар арасында йөреп ашау-эчүен дә оныта Алсинә апа.

Апас районының Әнәле авылыннан килен булып килгән ул. Ире белән өч ул тәрбияләгәннәр. Бик тырышып матур итеп йорт җиткезгәннәр. Уллары да әниләре үстергән гөлчәчәкләр арасында хозурланып йөрергә ярата икән.
– Төпчек улымның әле укырга кермәгән чагы иде. Беркөнне яныма йөгереп килгән бу: «Әни, анда бер гөл 20ләп чәчәк аткан», – ди, сөенеп. Үзе саный да белми. Күп булгач, исе киткән. Минем ярату улларыма да күчкән, – ди 67 яшьлек Алсинә апа.
Төп йортта ире Рифкать абый белән яши ул. Ире биш ел элек инсульт кичергән. Шуннан бирле сөйләшә алмый икән. Җәен Рифкать абыйга иртүк ашарга әзерли дә бакчасына чәчәкләр янына ашыга хуҗабикә. Илледән артык төрле чәчәкнең һәрберсен тәрбиялисе бар чөнки. Арада роза, гортензия, пион, хризантема, петуния, ромашка, лилия, кашкарыйлар да бар. Өе дә гөлләр белән тулган. Тәрәзә төпләрендә – төрле төстәге бегония, цикламен. Халык телендә, гөл әйбәт үссен өчен, ботагын урлап утыртырга кирәк, диләр. Алсинә апа күрмәгәндә генә яфрак-ботакларын чәлдерәләр икән. Кул китүдигән нәрсәгә ышана ул.
– Кая гына барсам да, беренче булып, чәчәк кибетенә керәм. Ятрак орлыклар сатып алам. Аларның бөреләнүен, чәчәк атуын түземсезләнеп көтәм. Матурлыкка сокланам, чәчәкләрем белән сөйләшәм. Аерып кына атардай яраткан чәчәгем юк, – ди ул. – Күз булуга карамастан, дәлияләр һаман чәчәктә. Югыйсә бәрәңгеләрен кышка әзерләп куяр вакыт җитте. Әмма кырау сукмыйча, берсенә дә кагылмыйм.

Сәрия МИФТАХОВА

ИСЕНДӘ ТОТ!
Гортензия известьлы әче туфрак ярата. Төпләренә ылыс ботаклары күмәргә мөмкин. 10 литр суга 100 грамм лимон кислотасы салып болгатып, шул катнашманы чәчәк атканда сибү файдалы. Гөл төпләренә кадак салырга да була, чөнки аларга да тимер кирәк.

Тәмле булсын!

Балан бәлеше

Мәрьям МИННЕГУЛОВА рецепты

Камыр. Ярты стакан эретелгән атланмайны бер стакан он белән бутыйбыз. 200 г кефир яки оеган сөткә бер аш кашыгы шикәр комы, ярты чәй кашыгы тоз, бер аш кашыгы каймак, бер чәй кашыгы коры чүпрә (алдан бераз су белән шикәр комы салып күпертеп алам) һәм он салып камыр басабыз.

Эчлек. 2 стакан баланны ярты стакан суга салып, бер стаканнан артык шикәр комы, өч аш кашыгы он салып, куерганчы пешерергә.
Бәлеш, мичнең көенә карап, 40 минут чамасы пешә.

Гөбәдия өчен тәмле камыр

Гөлнар МӨЛЕКОВА рецепты

Майны өй температурасында йомшартасы. Аннары аны он белән бутап, «валчык» ясарга кирәк. Шуңа бер стакан кефир, коры чүпрә, чама белән тоз, шикәр комы салып озак итеп камыр басабыз. 30 минутка суыткычка куеп, камырны ял иттергәннән соң ясый башлыйбыз. Бик тәмле, затлы камыр була.

Файдалы

«Сәламәтлек банкасы»

Күзен авыруларга бирешмәс өчен, «сәламәтлек банкасы»н әзерләп куйсагыз, файдасын күрми калмассыз. Ансат кына ясала, тәмле һәм файдалы да.
Кирәк: 400 г бал, 3 данә лимон, 250 г чамасы имбир.
Кабыгы әрчелгән имбир белән төшләре алынган лимонны иттарткычның вак тишеклесеннән чыгарырга яки блендерда вакларга. Аннары яхшылап бал салып болгатырга. Шуны көненә 1–2 чәй кашыгы кулланырга кирәк.

10	20	30	40	50	60	70	80	90	100
110	120	130	140	150	160	170	180	190	200
210	220	230	240	250	260	270	280	290	300
310	320	330	340	350	360	370	380	390	400
410	420	430	440	450	460	470	480	490	500
510	520	530	540	550	560	570	580	590	600
610	620	630	640	650	660	670	680	690	700
710	720	730	740	750	760	770	780	790	800
810	820	830	840	850	860	870	880	890	900
910	920	930	940	950	960	970	980	990	1000

Лайфхак

Акча җыйганны ярата

Әгәр күптәннән нидер алырга кызыгып, һаман акча туплый алмыйсыз икән, әлеге ысулны кулланып карагыз. Шушы ысул ярдәмендә 100 көн эчендә 50500 сум акча тупларга була.
Моның өчен түбәндәге таблицаны кисеп, суыткыч ишегенә беркетеп куегыз. Мәсәлән, берәр банка яки копилкага 10 сум акча салгач, «10» дип язылган шакмакны сызып куясыз. Монда тәртип буенча бару мөһим түгел. Хезмәт хакы алганда күбрәк, акча «кысылып» киткәндә азрак салырга була.

ЫШАНУ ДА, КУРКЫТУ ДА – ГӨНАҺ

Кашык төшсә, кунак килә. Тоз түксәң, өйдә тавыш чыга. Каршыңнан кара мәче йөгереп узса, юлың уңмый. Көндәлек тормышта бу сүзләрне еш ишетергә туры килә. Берәүләр, ырым-шырымга ышану – гөнаһ, дисә, икенчеләре шуларның рас килүеннән куркып яши. Чынлыкта кайсы як хаклы? Ырым-шырымга ышану, аның белән куркыту гөнаһмы?

pinterest.com

Башкортстанның Илеш районы «Тәүбә» мәчетеннән Артур хәзрәт ГАБДУЛЛИН белән шул хакта сөйләштек.

:: Ырым-шырымга ышану пәйгамбәребез яшәгән заманда да булганмы?

– Әлбәттә, булган. Ислам дине таралганчы ырым-шырымнар халыкта киң таралган булган. Мисал өчен, кеше нинди дә булса эш башкарыр алдыннан кулына берәр кош-корт яки хайван алган да ул уң якка китсә, эшкә тотынган, сулга китсә, бу ниятеннән кире кайткан. Шушы чорда аеруча киң таралган ырымнарның берсе бу. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Сез һичшиксез сезгә тиклем яшәгән халыкларның йолалары, сынамышлары артыннан барырсыз. Хәтта алар җирдәге хайванның оясына керсәләр дә, сез дә алар артыннан шул ояга керәчәксез», – дигән. Шунда пәйгамбәребездән: «Син яһүдләр һәм христианнар турында әйттеңме?» – дип сораганнар. Ул үз чиратында: «Тагын кемнәр турында булсын инде», – дигән.

Менә шушы 1,5 мең ел элек әйтелгән сүзләр бүгенге тормышыбызда чагыла. Бүген үзен мөселман дип санаган кешеләр, үзләре дә аңламыйча, яһүдләр һәм христианнардан килгән нинди дә йолалар, сынамышларга ияреләр. Бу инде белем җитмәүдән барлыкка килә. Ырым-шырымга ышану – динебездәге иң куркыныч гөнаһларның берсе. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ырым-шырымга ышану сәбәпле, кем дә булса нинди дә эшен калдырса, ул ширк кылган була», – дигән. Димәк, ырым-шырымга ышану ширк булып тора. Ник дигәндә, Җир йөзендәге бар нәрсә Аллаh рөхсәте белән генә була. Төрле ырым-шырымга ышанган вакытта исә без нәрсәне дә булса Аллаһы Тәгаләгә тәңгәл куябыз.

:: Бүген, ягъни 20 октябрьдә агачта яфраклар коелып бетмичә, кар яуса, тиздән ул эреп бетәр, диләр. Мөселман кешегә мондый сынамышларга ышанырга ярыймы?

– Әгәр шушы мәсьәләләр фән ягыннан дәлилләнгән икән, ул инде сынамыш түгел, ә чынбарлык була. Димәк, аңа ышанырга ярый. Әйтик, кош түбән очса, яңгыр явачак дигән әйтем бар. Фәнни яктан бу күренеш өстә басым югары булу белән аңлатыла. Димәк, халык сынамыш буларак кабул иткән бу гыйбарәгә ышанырга мөмкин. Ә инде сынамыш кеше үзе уйлап чыгарган буш сүз генә икән, ул очракта аңа ышанырга ярамый. Әйтик, бусага аша күрешергә ярамый, диләр. Әмма ни өчен ярамаганлыгын беркем дә аңлатып бирә алмый. Бу фәнни яктан да расланмаган. Димәк, мөселман кешесенә аңа ышану да тыела.

:: Кашык төшеп китсә, кунак килә. Ишекне бикләп чыгып киткәннән соң нәрсәнедер онытып, өйгә кире керсәң, юлың уңмый, диләр. Бу сынамышлар көндәлек тормышыбызда аеруча кулланыла. Ни гаҗәп, алар еш кына чынга да ашып куя. Әйтик, кайчак кашык төшеп китсә, дөрестән дә йортка кунак килә. Бу ни өчен шулай килеп чыга икән? Очраклылыкмы бу? Әллә инде кайбер сынамышлар чынлап та тормышка ашарга сәләтлеме?

– Болар шулай ук алда телгә алынган тыелган ырым-шырымнар рәтенә керә. Аларны фәнни яктан берничек тә аңлатып булмый. Кешенең кашыгы төшеп киткән дә өенә кунак килеп кергән, ди. Аллаһы Тәгалә шул рәвешле кешеләрне сынарга да мөмкин. Ничек сыный? Кеше нинди дә ырым-шырымга ышана, ә аңа алай эшләргә ярамый, дип әйтәләр. Шуннан Аллаһы Тәгалә моны сыный: кашыгы төшеп китә дә өйгә чынлап кеше килеп керә. Бу очракта кеше ни эшләр: теге сынамышка ышанырмы, әллә аңа әйтелгән кисәтүне истә тотып, аны ширк итеп кабул итәрме? Аллаһы Тәгалә шуны күзәтә. Сынамышның чынга ашуы очраклылык та була ала.

:: Зиратта урын алып калсаң, үлемеңне якынайтасың, диләр. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Бүген мәет җирләүгә бәйле бик күп ырым-шырымнар белән очрашырга туры килә. Зиратта урын алып калсаң, үлемеңне якынайтасың, диләр. Зираттан киемеңә ияргән балчык алып кайтсаң да, үлемеңне тизләтәсең, диләр. Мондый ырым-шырымнар – зур гөнаһ. Мәет җирләүне, озатуны без фәкать Аллаһы Тәгаләнең кануннарына һәм пәйгамбәребезнең сөннәтенә генә нигезләнеп эшләргә тиеш. Әгәр Коръәндә, хәдисләрдә фәлән әйбердән куркырга дигән боерык юк икән, шул гамәлне тыныч күңел белән эшлисең. Мондый ырым-шырымнар кешенең тормышын бик авырайта. Шуңа күрә аларны ишеткәч, кеше бер мәлгә туктап, бераз башын эшләтергә, уйланырга тиеш. Шул ук зиратта урын алып куйсаң, үлемеңне якынайтасың дигән гыйбарәне генә алыйк. Үлем безгә кемнән килә? Әлбәттә, Аллаһы Тәгаләдән. Безгә яшәү вакытын кем куя? Аллаһы Тәгалә. Безне дөньяга кем китерә? Аллаһы Тәгалә. Чирен, сынавын да Ул бирә. Шулай булгач, зиратта урын алып кую нигә кеше гомерен кыскартырга тиеш?

:: Кайбер кеше ырым-шырымнар ярдәмендә кешегә басым ясарга ярата. Фәлән итсәң, төгән була, дип гел тукып, куркытып тора. Хорафатларны диндә язылган кагыйдә, дип ышандырырга тырышучылар да очрый. Болай эшләү дөресме? Икенче бер кешене ырым-шырым ярдәмендә куркыту гөнаһмы?

– Кешене шул рәвешле куркыту дөрес түгел, билгеле. Кешене бераз куркытасың, аңа нәсыйхәт кыласың килсә, бу гамәлләрне Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткән ысуллар белән генә эшләргә кирәк. Мәсәлән: «Аллаһы Тәгалә Коръәндә шулай дип әйтә, шуңа бу гамәлне эшләргә ярамый. Аны эшләгән кешене фәлән җәза көтә», – дип әйтергә мөмкин. Ә инде кешене нинди дер хорафатлар аша куркыту икеләтә гөнаһ була. Андый кешеләр еш очрый. Кайберәүләр үзен мөселман дип бөтенләй башка дин, милләт вәкилләренең сынамышларын, йолаларын, ырым-шырымнарын сөйләп, шуңа ышандырып йөри. Бу – бик зур гөнаһ.

Риваять

Җәннәт нидән яратылган?

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Ул пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Җәннәт нидән яратылды?» – дип сораган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Судан», – дип җавап биргән. Без: «Җәннәт бинасы хакында хәбәр бир», – дидек. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Бер кирпече алтыннан, бер кирпече көмештәндер. Ул җәннәтнең балчыгы хуш исле яфрәдән барлыкка китерелгән, туфрагы – зәгъфран, ягъни ризыкка төс бирә торган тәмләткечтән, вак ташлары – энҗе һәм якут ташыдыр. Ул җәннәткә кергән кеше нигъмәтләнер һәм курыкмас, анда мәңге калыр – үлмәс, аның киемнәре искермәс, яшьлеге фани булмас».

Моннан соң пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Өч кешенең догасын Аллаһы Тәгалә кабул кылыр. Болар – гадел патша, ураза тотучының ифтар вакытында кылган догасы, золым кылынган кешенең догасыдыр, чөнки ул золым кылынган кешенең догасы болыттан югары күтәрелер, ул догага Аллаһы карар һәм: «Әй золым кылынган бәндәм, Үземнең олуглыгым белән ант итәм, әлбәттә, соңрак булса да, сиңа ярдәмемне бирермен», – дип әйтер.



Йөгез, бер дога!

ҺӘРВАКЫТ ҺӘМ ҺӘР УРЫНДА УКЫРГА МӨМКИН

«Әлхәмдүлилләәһи галәә күлли хәәлин фәиннәһү мухәввилүл-әхвәәл. Раббәнәә әәтинәә фид-дүнйәә хәсәнәтән вә фил-әәхы-рати хәсәнәтән вә кыйнәә гәзәә-бән-нәәр. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин».

Мәгънәсе: «Һәр хәл өчен Аллаһы Тәгаләне мактыйбыз, чөнки хәлләрне үзгәртүче Ул. Йә, Раббым, безгә дөньяда да, Ахирәттә дә изге хәлләрне насыйп ит. Шулай ук безне җәһәннәм газабыннан сакла, Әй, Рәхмәтле Аллаһы, бөтен нәрсә Синең рәхмәтеңдә».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Мин = милләт

Асыл

ДИЛӘРӘ ДАМАР, ТАТАР, 25 ЯШЬ

Диләрә – активист, Татарстан халыкларының Яшьләр ассамблеясы рәисе урынбасары. Димәк, үзе турында гына түгел, күпмилләтле республикада яшәүче яшьләр турында да уйларга кирәк аңа.

Мөмкинлек булган саен, көндәлек образымны **МИЛЛИ ЭЛЕМЕНТЛАР** – бизәнү әйберләре, баш киемнәре, кечкенә орнаментлар белән тулыландырырга тырышам. Шөкер, бүген **МИЛЛИ КИЕМНЕҢ АКТУАЛЬ ҺӘМ КӨНДӘЛЕК ТОРМЫШТА ДА УРЫНЛЫ** була алуын раслаучы дизайнерлар шактый.

Мин – күпмилләтле гаиләдән. Әтием – төрек, әнием – татар. **МИНДӘ ИКЕ МИЛЛӘТ КАНЫ АГА, ИКЕСЕН ДӘ БИК ХӨРМӘТ ИТӘМ**. Күбесенчә татар телендә сөйләшсәм дә, безнең гаиләдә ике телне дә ишетергә мөмкин. Без ике милләтнең дә мәдәниятенә, гореф-гадәтләре һәм традицияләренә ихтирам белән карыйбыз, аларны саклыйбыз. **МИН ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК МИЛЛӘТЕННӘН БУЛУЫМНЫ КҮРСӘТӘ АЛУЫМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ**.

Тел ул – халыкның, милләтнең иң зур хәзинәсе. Нәкъ менә телдә безнең милли код саклана. **ТӘҮГЕ СҮЗЛӘР, БИШЕК ЖЫРЛАРЫ, БАЛАЛАР ӘКИЯТЛӘРЕ – БАРЫСЫНЫҢ ДА НИГЕЗЕНДӘ – ТУГАН ТЕЛЕБЕЗ**. Шуңа күрә үз телеңне саклап калу, үз телеңдә сөйләшү мөһим. Хәтта туган җиреңнән еракта булсаң да, туган телеңне онытмаска кирәк.

Балаларым белән фәкать туган телемдә аралашырга ниятлим. Аларга җырлар җырлап, әкиятләр сөйләп, телебезнең матурлыгын сеңдерәсем килә. Миңа калса, **ТЕЛГӘ, МӘДӘНИЯТКӘ, ТРАДИЦИЯЛӘРГӘ КАРАТА МӘХӘББӘТ ҺӘМ ХӨРМӘТ ГАИЛӘДӘН БАШЛАНА**.



Милләт ул – синең тамырларың, күп еллар дәвамында язылган һәм буыннан-буынга тапшырыла торган тарих. **АДӘМ БАЛАСЫ МИЛЛӘТЕ ҺӘМ ТУГАН ТЕЛЕ БЕЛӘН ДӨНЬЯГА АВАЗ САЛУГА БӘЙЛӘНӘ**.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде. Фото: Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

25 октябрь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Синең күзләр» 16+
11.00, 00.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «Департамент» 16+
13.00, 00.25 «Жырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «Синең күзләр» 16+
17.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «Исчезнувшая» 16+
01.15 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Сула!» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
09.30, 03.30, 04.20 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Кунак БиТ шоу» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 02.40, 22.20 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 12+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «Бизон: дело манекенщицы» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ЗЕРКАЛО ЛЖИ» 16+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Голевая неделя. РФ» 6+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 18.30 Новости
07.05, 15.30, 18.35, 00.00 Все на Матч!
10.05, 12.35, 03.05 Специальный репортаж 12+
10.25 «Кто кого?» 12+
11.25 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 6+
13.00 «Есть тема!»
15.00 «Вид сверху» 12+
16.25 «Я – Златан» 12+
19.30 Футбол. Лига чемпионов. «Фейеноорд» (Нидерланды) – «Лацио» (Италия)
21.45 Футбол. Лига чемпионов. ПСЖ (Франция) – «Милан» (Италия)
01.00 Футбол. Лига чемпионов. «Янг Бойз» (Швейцария) – «Манчестер Сити» (Англия) 6+
03.00 Новости 0+
03.25 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Гремио» – «Фламенго»
05.30 «Что за спорт?» 12+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
22.15 «БАЛАБОЛ» 16+
00.55 «ДЕЛО ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.50 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.45 «Давай разведёмся!» 16+
08.45 «Тест на отцовство» 16+
10.55, 23.00 «Понять. Простить» 16+
11.55, 00.05 «Порча» 16+
13.00, 01.00 «Знахарка» 16+
13.30, 01.25 «Верну любимого» 16+
14.05, 01.50 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ЧУЖОЙ РЕБЁНОК» 16+
19.00 «ОСТАВЛЕННОЕ СЕРДЦЕ» 16+
02.15 «ЧУЖОЙ РЕБЁНОК» 16+
05.30 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «КРАПОВЫЙ БЕРЕТ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.45 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА» 12+
12.30, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
12.45, 13.25, 19.55 «По горячим следам» 16+
13.45, 15.05, 17.15 «ЛЕТУЧИЙ ОТРЯД» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «СВО: компоненты силы» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «БЛОНДИНКА ЗА УГЛОМ» 12+
01.55 «СЛЕДСТВИЕМ УСТАНОВЛЕНО» 12+
03.25 «Перелом. Хроника Победы» 16+
03.50 «ЛЕТУЧИЙ ОТРЯД» 16+

26 октябрь | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «Синең күзләр» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «Департамент» 16+
13.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Классный час» 16+
14.45 «Семь дней +» 16+
15.10 «Сөенеч» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Точка опоры» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Сокол-балобан» 12+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 16+
00.00 «Исчезнувшая» 16+
00.50 «Видеоспорт» 16+
01.15 «Азбука долголетия» 16+
01.30 «Туган җир» 12+
03.30 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 12+
03.55 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00 «Туган авылым» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
18.20 «Кунак БиТ шоу» 16+
19.15, 22.20, 02.40 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 12+
20.00, 00.15 «Tatarstan today. Дөньяга ачык» 12+
21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
23.10, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «Бизон: дело манекенщицы» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Россия и Запад на качелях истории» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ЗЕРКАЛО ЛЖИ» 16+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. Обзор тура 6+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 18.30 Новости
07.05, 15.30, 18.35, 00.00 Все на Матч!
10.05, 12.35, 03.05 Специальный репортаж 12+
10.25 «Кто кого?» 12+
11.25 Футбол. Лига чемпионов 6+
13.00 «Есть тема!»
15.00 «Большой хоккей» 12+
16.25 «Леннокс Льюис: Нерассказанная история» 12+
19.30 Футбол. Лига конференций. АЗ (Нидерланды) – «Астон Вилла» (Англия)
21.45 Футбол. Лига Европы. «Ливерпуль» (Англия) – «Тулуза» (Франция)
01.00 Футбол. Лига Европы. «Рома» (Италия) – «Славия» (Чехия) 6+
03.00 Новости 0+
03.25 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Сантос» – «Коритиба»
05.30 «Вид сверху» 12+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
22.15 «БАЛАБОЛ» 16+
00.55 «Поздняков» 16+
01.10 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
01.55 «ДЕЛО ЧЕСТИ» 16+
04.35 «Военно-исторические маршруты» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.10 «Давай разведёмся!» 16+
09.10 «Тест на отцовство» 16+
11.15, 23.15 «Понять. Простить» 16+
12.15, 00.15 «Порча» 16+
13.20, 01.10 «Знахарка» 16+
13.50, 01.35 «Верну любимого» 16+
14.20, 02.00 «Голоса ушедших душ» 16+
14.55 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА» 16+
19.00 «НОВЫЙ МУЖ НАШЕЙ МАМЫ» 16+
02.25 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА» 16+
05.25 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.20, 13.45, 15.05, 17.15 «ЛЕТУЧИЙ ОТРЯД» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «ОТРЯД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
12.45, 13.25, 19.55 «По горячим следам» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «СВО: компоненты силы» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ЛЮДИ НА МОСТУ» 12+
01.05 «НЕ ЗАБЫВАЙ» 16+
04.00 «ПОДКИДЫШ» 6+

27 октябрь | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.15 «Синең күзләр» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 15.45 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
14.45, 02.15 «Семь дней +» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.15 «Кто мы татары?» 12+
17.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Лада» – «Ак барс» 6+
21.00 «Туган җир» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «КВН РТ-2023» 16+
22.40 «Неадекватные люди» 16+
00.30 «Настя» 12+
02.00 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
02.45 «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» 16+
03.00 «Бир кулыңны» 16+
04.20 «Әдәби хәзинә» 16+
04.45 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара» 16+
08.00 «Җанкай-җанаш» 6+
08.30, 04.20, 18.20, 23.10 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 01.55 «Заман көзгесе» 16+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 01.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
19.15, 22.20, 02.25 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 12+
20.00 «Туган җир» 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Фантастика» 12+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Драгоценные истории» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
04.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем!» 16+
05.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обман веществ» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Судьба человека» 12+
16.30 «Прямой эфир» 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.55 «Истории Большой Страны» 12+
00.55 «КЛЮЧИ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Третий тайм» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 15.00, 21.45 Все на Матч!
10.05 «Небесная грация» 0+
10.25 «Кто кого?» 12+
11.25, 22.50 Футбол. Еврокубки 6+
12.35 «Лица страны» 12+
13.00 «Есть тема!»
15.30 Смешанные единоборства
19.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Торпедо» (Нижний Новгород) – «Автомобилист» (Екатеринбург)
00.00 «Вы это видели» 12+
01.00 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Виктор» (Россия) – «Машека» (Белоруссия) 6+
02.30 «Магия большого спорта» 12+
03.00 Новости 0+
03.05 Матч! Парад 16+
03.25 Дзюдо. Турнир «Большого шлема» 12+
05.30 «Большой хоккей» 12+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
09.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
22.15 «БАЛАБОЛ» 16+
00.00 «Своя правда» 16+
01.45 «Квартирный вопрос» 0+
02.40 «ОТСТЕГНИТЕ РЕМНИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 02.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.25 «Тест на отцовство» 16+
10.35, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.35, 00.30 «Порча» 16+
12.45, 01.20 «Знахарка» 16+
13.15, 01.45 «Верну любимого» 16+
13.45, 02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.20 «Скажи, подруга» 16+
14.35 «ИСКУПЛЕНИЕ» 16+
19.00 «УРОКИ ЛЮБВИ» 16+
23.05 «Уют за 15 минут» 16+
03.25 «6 кадров» 16+
03.35 «ИСКУПЛЕНИЕ» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «ЛЕТУЧИЙ ОТРЯД» 16+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.20 «ЛЮДИ НА МОСТУ» 12+
11.35, 13.25 «ДОСЬЕ ЧЕЛОВЕКА В «МЕРСЕДЕСЕ» 16+
14.50, 15.05, 17.15 «ЖАЖДА» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.40 «Загадки века» 12+
20.30 «Скрытые угрозы» 16+
21.20 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.15 «Музыка+» 12+
00.30 «ВА-БАНК» 16+
02.10 «ВА-БАНК 2, ИЛИ ОТВЕТНЫЙ УДАР» 16+
03.40 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+

28 октябрь | Шимбә

ТАТАРСТАН
08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30, 01.35 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 Ж.-Б. Мольер. «Дон Жуан». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
17.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 6+
17.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00, 04.45 «Кәмит Җавит» 16+
19.00 «Халкым минем...» 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30, 03.55 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 Концерт фестиваля «Наше время – Безнең заман» 0+
00.00 «Ближе, чем кажется» 6+
02.00 «Сөю көтә йөрәк» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Кунак БиТ шоу» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.50 «Яратам» 16+
17.15 «Казаннан – Казанга» 16+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Олы юл әйтте...» 16+
22.10 А.Галин. «Сагыш» Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
00.10 Т.Миңнуллин. «Саташу». Чаллы татар дәүләт драма театры спектакле 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Насыйхәт» 16+

1 КАНАЛ
06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Наше всё» 12+
11.05 «ПроУют» 0+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Старший сын» 12+
15.45 «Горячий лед». Фигурное катание. Гран-при России 2023. Короткая программа
16.55 «Мир на грани. Уроки Карибского кризиса» 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Михаил Задорнов: вся жизнь» 16+
19.15 «Эксклюзив» 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.15 Лига Ставок. Алексей Папин – Сослан Асбаров
00.15 «Мир глазами группы Radiohead» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
02.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
04.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
05.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.50 «В кругу друзей»
12.50 «Доктор Мясников» 12+
14.50 «Юморина» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «КВАРТИРКА» 16+
01.00 «ЦВЕТОЧНОЕ ТАНГО» 12+
04.25 «ОЖЕРЕЛЬЕ» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 «География спорта. Химки» 12+
06.30 «РецепТура» 6+
07.00, 15.30 Новости
07.05, 13.45, 15.35, 18.30, 20.55, 23.45 Все на Матч!
09.55 «Я – Златан» 12+
11.55 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Тюмень» – КПРФ (Москва)
13.55 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Чеховские медведи» (Россия) – «СКА Минск» (Белоруссия)
16.15 Футбол. МИР РПЛ. «Крылья Советов» (Самара) – «Оренбург»
18.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит-Казань» – «Динамо» (Москва)
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Ювентус» – «Верона»
00.25, 03.25 Футбол. Чемпионат Бразилии
02.30 Матч! Парад 6+
03.00 Новости 0+
03.05 «Небесная грация» 0+
05.30 «Здоровый образ» 12+

НТВ
04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
07.30 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.10 «Попутчик» 16+
14.20 «Игры разумов» 0+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение» 16+
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион» 16+
23.25 «Международная пилорама» 18+
00.15 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
00.45 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Эрика Лундмоен 16+
02.05 «Дачный ответ» 0+
03.00 «ОТСТЕГНИТЕ РЕМНИ» 16+
04.35 «Военно-исторические маршруты» 16+

ДОМАШНИЙ
10.15 «Пять ужинов» 16+
10.30 «ПЕРЕЗВОНЮ ПОЗЖЕ» 16+
14.45 «БЕЗ ТЕБЯ МНЕ ЖИЗНИ НЕТ» 16+
19.00 «ЯРКОЕ ПЛАМЯ» 16+
22.40 «Скажи, подруга» 16+
22.55 «БЕГИ, НЕ ОГЛЯДЫВАЙСЯ!» 16+
02.35 Эффект Матроны 16+

ЗВЕЗДА
05.10 «БАЛАМУТ» 12+
06.40 «НА ЗЛАТОМ КРЫЛЬЦЕ СИДЕЛИ...» 6+
08.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.20 «Освобождение» 16+
09.50 «МЕДОВЫЙ МЕСЯЦ» 12+
11.40 «Легенды музыки» 12+
12.10 «СССР. Знак качества» 12+
13.15 «Не факт!» 12+
13.40 «Война миров» 16+
14.30 «Легенды кино» 12+
15.20 «Время героев» 16+
15.45 «Главный день» 16+
16.35, 19.25, 03.15 «ФРОНТ ЗА ЛИНИЕЙ ФРОНТА» 12+
20.45 «ФРОНТ В ТЫЛУ ВРАГА» 12+
23.55 «ДОСЬЕ ЧЕЛОВЕКА В «МЕРСЕДЕСЕ» 16+
02.05 «Неизвестная война. Великая Отечественная» 16+
02.55 «Москва фронту» 16+

29 октябрь | Якшәмбе

ТАТАРСТАН
08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Гомер – татлы мизгел» 16+
08.00 «Адымнар» 16+
08.30 «Полосатая зебра» 0+
08.40 «Сөенеч» 0+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Сәләт» 0+
10.15 «Дуслык илендә» 12+
11.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.00 «Адымнар» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.45 «Наша Республика – наше дело» 16+
14.45 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.45 «Ком сәгате» 16+
16.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» – «Ак барс» 6+
19.30 «Семь дней» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.00 «Профсоюз – союз сильных» 12+
21.15 «Батырлар» 6+
21.30 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
22.30 «Семь дней» 16+
23.30 «Видеоспорт» 16+
00.00 «Особые приметы: красавчик» 16+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
07.00, 02.45 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 «Кыр казларын бергә каршылыйк» 16+
09.00, 14.20, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00, 03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 12+
13.20, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.50 «Tatarstan today. Дөньяга ачык» 12+
15.20 «Гомерләрне үлмәс җыр итеек» 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
17.15, 05.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җавит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 Р.Вәлиев. «Әйдә барыйк, кызлар карыйк». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 16+
01.05 «Манзара» 16+

1 КАНАЛ
06.00, 12.00 Новости
06.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.00 Новости
10.15 «Жизнь своих» 12+
11.10 «Повара на колесах» 12+
12.15 «Видели видео?» 0+
14.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
15.20 Фигурное катание. Гран-при России 2023. Произвольная программа
17.05 Специальный репортаж 16+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Перепой звезду» 12+
21.00 «Время»
23.00 «Кислород. Вверх за пределы себя» 12+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Летописи конца времен» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
04.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем!» 16+

РОССИЯ 1
06.10, 01.30 «НЕЛЁГКОЕ СЧАСТЬЕ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
12.00 «Большие перемены»
13.00 «СВАДЕБНЫЙ МАРШ» 16+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 «Магия большого спорта» 12+
06.30 «Что за спорт?» 12+
07.00, 12.40, 15.30 Новости
07.05, 12.45, 15.35, 18.30, 00.45 Все на Матч!
10.00 «Лига героев» 12+
11.05 «Фетисов» 12+
13.25 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
13.55 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. ЦСКА – «Астраханочка» (Астрахань)
16.25 Бокс. Международная матчевая встреча. Россия – США
19.00 Футбол. МИР РПЛ. ЦСКА – «Краснодар»
21.30 После футбола
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Наполи» – «Милан»
01.30 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Зенит» (Россия) – «Гомель» (Белоруссия) 6+
03.00 Новости 0+
03.05 «Лица страны» 12+
03.25 Футбол. Чемпионат Бразилии
05.30 «Здоровый образ» 12+

НТВ
04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Ты супер! Суперсезон». Финал 6+
23.35 «Звезды сошлись» 16+
01.10 «Основано на реальных событиях» 16+
02.30 «ОТСТЕГНИТЕ РЕМНИ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «БЕГИ, НЕ ОГЛЯДЫВАЙСЯ!» 16+
10.15 «Уют за 15 минут» 16+
10.30 «ПОКА ИДУТ ЧАСЫ» 16+
14.50 «ПОСТУЧИСЬ В МОЮ КАЛИТКУ» 16+
19.00 «ЯРКОЕ ПЛАМЯ» 16+
22.40 «Твой Домашний доктор» 16+
22.55 «ПРОШУ ПОВЕРИТЬ МНЕ НА СЛОВО» 16+
02.40 «6 кадров» 16+
03.15 Эффект Матроны 16+

ЗВЕЗДА
06.05 «ФРОНТ В ТЫЛУ ВРАГА» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка». 12+
10.40 «Скрытые угрозы» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» 12+
13.10 «Специальный репортаж» 16+
13.50 «Освобождение» 16+
14.25 «ЖАЖДА» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
22.40 «Москва фронту» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «Люди Донбасса» 16+
00.00 «ДЕРЗОСТЬ» 12+
01.40 «МЕДОВЫЙ МЕСЯЦ» 12+
03.10 «Военные врачи» 16+
03.45 «СМЕРШ. ЛЕГЕНДА ДЛЯ ПРЕДАТЕЛЯ» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Россия мәгълүмат телеграф агентлыгы» федераль дәүләт унитар предприятиесенең (ИТАР-ТАСС) үз фотохәбәрчесе (Казан ш.) **Алеев** Егор Александровичка Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президенты Рәхмәте** белдерелде.

«Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы инспекторы-методисты **Әхмәтҗанов** Айнур Артур улына, «Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы рәисе урынбасары **Рябов** Андрей Александровичка, Казан шәһәренең «Идел» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тренеры **Галиәскәров** Роберт Галиәскәр улына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Зилант» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Фәйзуллин** Рөстәм Гыйният улына, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалы директоры урынбасары **Казакова** Илзидә Искәндәр кызына, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалы директоры урынбасары **Парамонов** Андрей Ивановичка, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе ярдәмчесе **Хөсәенова** Энҗе Мәсхүт кызына, «Торак төзекләндерү һәм төзү участогы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гыймалетдинов** Фатыйх Равил улына, «ДомСтрой» төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре җитәкчесе **Евстигнеев** Андрей Анатольевичка, «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры урынбасары **Мусаев** Александр Әсхәт улына, «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре җитәкчесе **Селезнев** Михаил Александровичка, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы төзелеш комплексын үстерү идарәсенең торак төзелеше бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Харисова** Фирая Фәрит кызына, «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җитештерү-техник бүлеге башлыгы **Яфизов** Эмиль Наил улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җинаятьчеләрне эзләү идарәсе автомототранспортны куып алып китү һәм урлау җинаятьләрен ачу бүлегенең аеруча мөһим эшләр буенча өлкән оперуполномоченные, полиция майоры **Борһанов** Фәрит Фаил улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсе 1 номерлы «Автозавод» полиция бүлегенең җинаятьчеләрне эзләү бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы **Силиванов** Денис Сергеевичка, «Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең хезмәтне саклау буенча белгече, укытучысы **Әхмәтҗанов** Руслан Нургаяз улына, «Казан приборлар төзү конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте генераль директоры **Курбиев** Илдус Өлфәт улына **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

НӘСЕЛ КӨЧЕ

pinterest.com

«Нәкъ әнисе!», «Атаң булсаң булырсың икән!», «Әбиең дә гел шулай итә торган иде». Моның ише сүзләрне ишетергә дә, әйтергә дәияләнеп беткән инде без. Туганыңа охшау – гаҗәп хәл түгел. Нәсел эчендә язмышларның кабатлануына кайчак игътибар да итмибез. Ә инде тирәнрәк уйланып, нәселеңне өйрәнә башласаң, күп нәрсәнең асылына төшенәсең икән...

Хаталар кабатланмасын

Нумеролог Резидә Әлмиева әлеге теманы үзлектән өйрәнә башлаган. Беренче чиратта, нәселендәге хатын-кызларның язмышлары охшаш булуына игътибар иткән ул.

– Төгәлрәк әйтсәк, барысын да бер үк төрле проблемалар сагалый. Әйтик, аларның барысына да хыянәт итәләр, я булмаса, аларның ирләре юк. Ике туганның бер үк датада тууы, исемнәрнең бер үк булуы да ике язмышны охшаш итә – моңа да игътибар иттем. Бу миңа кызык булып тоелды да әлеге теманы өйрәнә башладым, – ди ул.

Нәсел тарихын белмәү кешене билгесезлектә яшәтә, ялгышларны кабатлата. Резидә әнә шул фикердә.

– Безгә тәрбияне әти-әниебез һәм туганнарыбыз биргән. Без аларның фикерләрен, куркуларын, инануларын сеңдергәнбез. Әйтик, буыннан-буынга «ир-атларга ышанырга ярамый» дигән фикер күчеп бара ди. Бу – туганнарыбызның аянычлы хәлләр кичергәндә туплаган тәҗрибәсе. Ләкин ул бүгенге шартларга туры килмәскә мөмкин. Безгә мондый инанулардан «качарга» кирәк. Ләкин син аның чыганагын белмисең икән, билгесезлектә яшәвеңне дәвам иттерәчәксең. Моннан тыш, без гаиләбезнең күп кенә серләрен белмибез. Әйтик, безгә хыянәтләр, өйдәге җәберләүләр, үз-үзенә кул салучылар, кыскасы, җәмгыять һәм дин тарафыннан кабул ителми торган гамәлләр турында сөйләмиләр. Ә бит без аларны белсәк, хаталар кабатланмас иде, – ди Резидә.

Нәселе белән элемтәне ныгыту өчен, Резидә нәрсә эшли соң?

– Туганнарың белән ешрак очрашырга, сөйләшергә, аларны бергә җыярга кирәк. Мин, мәсәлән, фотоальбомнар ясыйм. Нәселең турында китап язарга, туганнарны, авылдашларны җыеп, бәйрәмнәр оештырырга да була. Нәселе белән элемтәләре нык булган кеше тормыштагы күп хәлләргә әзер була. Кая барса да, аңа ниндидер көч ярдәм иткән кебек тоелачак. 7 буынын белгән кеше үзен якланган кебек хис итә, ул аның ДНКсына салынган, – дип аңлатты ул.

Маяк

Резидәнең фикерләрен журналист Альберт Шакиров та дәвам итте. Ул да, җиде буын бабаңның кем булуын гына түгел, аларның горурланырлык һәм оялырлык якларын да белергә кирәк, ди.

– Нәселне белү – безнең канга сеңгән әйбер. Ул дәрәҗәңне күрсәтү өчен генә түгел, үзеңне кулда тотарга өстәмә контроль өчен дә кирәк. Без нәселебезне төрле яклап беләбез икән, безнең бүген кылган гамәлләрне дә кимендә җиде буын оныкларыбыз хәтерләячәк дигән сүз. Эшләдем дә бетте, беркем искә алмаячак, дип, хәзерге көн белән яшәү – бер нәрсә. Ә кем булганыңны киләчәк буыннар да белачәген уйласаң, үзеңне башкачарак тота башлыйсың, – дип сөйләде Альберт Шакиров.

Нәселеңне белү аяктa ныграк басып торырга булыша, дип, фикерен дәвам иттерде ул.

– Моннан ике-өч ел элек бер зур программа кысасында генетик тест эшләттек. Шуннан без чама белән ниндирәк төркемгә каравыбызны, үзенчәлекле якларыбызны белдек. Моннан 1500 еллар элек Европа якларыннан монда күченеп килүчеләргә барып тоташа икән безнең ДНК. Мондый мәгълүматка ия булу рухи яктан терәк бирә, «Мин кем булырга, кайсы якка барырга тиеш?» кебек сорауларга ачыклык кертә. Үзенә күрә маяк булып тора, – диде журналист.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Өзелмәсен җеп

Нәсел көче – нәрсә ул? Ата-бабаларыбыз безне ничек саклый? Нәселе белән элемтәсен югалткан кешегә нәрсә яный? Бу һәм башка сорауларны без нәсел белгече, шәҗәрә төзү буенча консультант Диләрә ГАФИЯТУЛЛИНАга бирдек.

– 1000ләп кешене берләштергән дүрт шәҗәрә төзегәнсез. Бу эшкә нәрсә этәрде сезне?

– Дөресен генә әйткәндә, документларны, фотоларны тәртипкә салырга кирәк, дип тотынган җирдән башланган эш ул. Башта әти-әнием ягыннан шәҗәрәмне төзедем. Кияүгә чыккач, иремнең әти-әнисенең әби-бабаларын барлый башладым. Шушы дүрт зур шәҗәрәне берләштереп, балабыз туды. Бу эшкә тотынганда, гадәти схема рәвешендә генә эшләрмен дигән идем. Психология, педагогика, генеалогия өлкәләрендә белемнәремне арттыра башлагач, курслар узгач, нәселемне тирәнрәк өйрәнә башладым. Нинди вакыйгалар булган? Алар безнең нәселгә ничек тәэсир иткән? Хәзер инде бу эштә башкаларга да ярдәм итәм. Нәсел өйрәнүнең ике тармагы бар: генеалогия һәм родология. Генеалоглар күбрәк архивларда эшли, кайчан һәм нәрсә булганын ачыклый. Родологлар исә булган вакыйгаларның нәселгә нинди йогынты ясавын өйрәнә. Родология рәсми рәвештә психологиянең бер тармагы буларак теркәлгән, ул эзотерикага бәйле фән түгел.

– Сезгә мөрәҗәгать итүчеләр күпме?

– Күбесенчә шәҗәрә төзү максатыннан киләләр. Кемдер шуның белән туктала. Ә кемдер, әби-бабалары кичергән вакыйгалар белән бүгенге вакыйгалар арасында бәйләнеш табып, тагын да тирәнрәк өйрәнә башлый. Бу бәйләнеш юктан гына барлыкка килми бит. Тагын шунысы кызык: нәсел тарихыңны өйрәнгән вакытта, туган телеңдә эш итү мөһим. Без бит инде хәзер – ике телле буын. Ә әби-бабаларыбыз фәкать туган телебездә сөйләшкән. Алар әйткән сүзләрне, фикерләрен, ышануларын бөтен тирәнлеге белән аңлау өчен, без дә үз телебездә эшләргә тиеш.

– Нәселен өйрәнү кешегә ничек ярдәм итә?

– Беренче чиратта, үзең турында күбрәк беләсең. Кешелек дөньясы һәрвакыт «Мин монда кем?», «Мин монда нәрсә өчен килдем?», «Нинди эз калдыра алам?» сорауларына җавап эзли. Үз тарихын белгән кеше мондый сорауларга җавапны җиңелрәк таба. Үз гамәлләренә, теге яисә бу вазгыятьтә үз-үзен тотышына дөрес бәя бирә ала.

– Нәсел белән элемтә дигән нәрсә дә бар бит әле. Аны ничек булдырырга?

– Нәселең, гаиләң кичергән вакыйгалар турында мәгълүмат туплаганнан соң, бу мәгълүматка тиешле бәя бирергә кирәк. Син ул вакыйгаларга тәнкыйть түгел, ихтирам белән карарга, рәхмәтле булырга тиеш. Шул очракта нәселең белән элемтә барлыкка киләчәк. Нәселгә карата гаеп, үпкә хисләре бу элемтәне өзә. Әби-бабаларыбызның кылган гамәлләре, алар кабул иткән карарлар – барысы да дөрес. Башкача без һәм нәселебез исән булмас иде.

Бу элемтә тормышның төрле өлкәләренә йогынты ясый. Шәхси тормышта да, сәламәтлек, акча, эш ягыннан да үзгәрешләр башлана.

– Ә нәсел белән элемтәсен өзгән кеше ниләр кичерә?

– Кеше я нәселенә каршы бара, я аңа таянып яши. Ике очракта да мул, бәхетле тормышта гомер кичерергә була. Ләкин нәселе белән элемтәсен өзүченең балалары, оныклары ничек яшәр? Менә анысы – икенче мәсьәлә. Бу элемтәне өзгәнче, шуны уйларга кирәк.

– Кайбер белгечләр кешедәге алдан тоемлау хисен дә нәсел көченә бәйли.

– Бик кызыклы мәсьәлә бу. Алай булырга мөмкин. Кешедә саклану инстинктлары актив – алдан тоемлау шуның белән аңлатыла. Шул ук вакытта сине нәселең дә саклый ала. Ләкин бу һәрвакыт яхшыга илтми. Әйтик, берәүнең әби-бабалары бик бай булган, рәхәт яшәгән, ләкин кулаклаштыру чорында күченеп йөрергә мәҗбүр ителгән. Ул кеше бүген шулай ук бер урында төпләнеп яши алмаска мөмкин. Тәҗрибәмдә мондый мисаллар булды. Андый кешеләр үзләрен югалган, нигезсез итеп хис итә. Әмма һәр гаилә төрле, вакыйгалар да, ул вакыйгаларга карашлар да, аларның бүгенге буынга йогынтысы да аерыла.

Фикер

Зөһрә КӘРИМОВА, клиник психолог:

– Психологиядә нәсел көче мөһим урынны алып тора. Ул кешенең куркуларына да, карашларына да, ышануларына да, дөнья һәм башка кешеләр белән элемтәләренә дә йогынты ясый. Без теге яисә бу психологик установкадан тиз генә котыла алмыйбыз, чөнки без аны әти-әниебез, әби-бабабыздан сеңдергән. Моннан тыш, кеше өчен якыннарының аңа карата булган фикере мөһим. Ул аңа иң төгәл, дөрес фикер булып тоела. Үз нәселен белгән кеше үзен яхшырак аңлый, кабул итә. Әмма бөтен кеше дә нәселе белән элемтәләрне җайлый алмый. Бу гаилә тарихында булган вакыйгаларны, әби-бабалары кылган гамәлләрне кабул итә алмау, аларга үпкә, ачу хисләре белән карауга бәйле. Бу хисләрне юкка чыгару өчен, билгеле, үз өстеңдә эшләргә кирәк.

Рәшид АМИШОВ, тарихчы:

– Гаилә, нәсел тарихлары турында китаплар язам. Билгеле, мондый эш вакытны күп ала. Бик күп мәгълүмат белән эшләргә, эзләнергә туры килә. Китап язар өчен, ким дигәндә, ярты еллап вакыт китә. Бәясе дә 200 мең сумнан башлана. Миңа калса, моны башкарган кеше үзе өчен дә, нәселе өчен дә, киләчәк буыннар өчен дә зур файда кыла. Нәселне өйрәнү психологик яктан, төгәлрәк әйтсәк, үзеңне аңлау өчен дә файдалы. Аннан соң «нәсел көче» дигән төшенчә бар. Ата-бабаларыбызга ихтирам күрсәтеп, алар хөрмәтенә изге эшләр башкарып, рухларына дога кылып, аларны шатландырабыз икән, тормышыбыз яхшыра, эшләребез дә уңа.

P.S. «Алма агачыннан ерак төшми» дигән гыйбарәне белмәгән кеше юктыр. Нәсел программалары буенча белгеч Сергей Кулаков аны менә ничек аңлата: «Барлык сорауларга да җавап табигатьтә бар. Безнең ата-бабаларыбыз моны яхшы аңлаган. Алмагачтан өзелеп төшкән җимеш еракка китә алмаган кебек, кешенең дә генофонды, ДНКсы нәсел системасының бер өлеше булып тора».

КӨТҮЧЕГӘ – ЧӘЧӘК БӘЙЛӘМЕ

Гел-гел эш димәгән. Бу юлы Чистай районының Татар Баганалысы авылына килеп чыккач, ничек ял итүләре,ниләр белән шөгыльләнүләре турында белештек әле. Кызып-кызып эшләгәннән соң, халыкны үзенә тартып торган җылы учак мәдәният йорты булып чыкты. Кызык та, файдалы да булсын дип, кичке утырмаларда ниләр генә эшләмиләр дә ниләр генә уйлап тапмыйлар икән биредә.

Зөлфия Хәлиуллина

«Матур Хәдичә»

Көннәрдән беркөнне Көтү бәйрәме уздыру идеясе дә шунда туган. Шәп кенә килеп чыккан ул. Әле дә сагынып искә алалар. Шулай булмый хәле дә юк инде. Авылда терлек асраучылар күп, шуңа күрә көтүләре дә шактый зур икән. Халык авыл башына сыер-сарыгын каршы алырга йөри. Әмма алар анда күбрәк сөйләшеп, аралашып алыр өчен җыела кебек.

– Башта иң матур сыер исеменә бәйге үткәрдек, – дип сөйли мәдәният йортында эшләүче кызлар. – «Матур Хәдичә» исемлесе беренче урынга лаек булды. Аннан соң көтү куарга дип алган таякларын тоттырып, апаларны бер рәткә тезеп куйдык. Бергәләп иң уңайлы, зәвыклы тоелган таякны сайлап алдык. Хуҗасына бүләк бирдек. Моңа кадәр «эш кораллары»на игътибар иткәннәре дә булмаган икән. Көн саен кулга тотып йөргән шул таякларын, беренче тапкыр күргәндәй, әйләндерә-әйләндерә карадылар, рәхәтләнеп көлештеләр. Малайлар исә чыбыркы шартлату ярышында көч сынашты. Шуннан китте инде. Хатын-кызлар бертуктаусыз көтүдә булган кызык хәлләрне искә төшереп сөйләделәр. Берзаман Наилә апа Әухәтова, зур савытка салып, пылау күтәреп чыкты. Кырыена кашыкларга кадәр тезеп чыккан. Мондый бүләкне үзебез дә көтмәгән идек. Шулай да иң кызыгы көтүчеләрне чәчәк бәйләмнәре белән каршы алу булды. Алар берни белми бит инде, көн буе кырда. Мондый хөрмәтне күргәч, ни булган икән дип, күзләре маңгайларына менде, аптырашып калдылар. Авылыбыз белән көлештек.

Кызлар-йолдызлар

Кызлар дигәннән, мәдәният йортында алар өчәү. Венера Гатиятуллина – методист, Гөлнара Сөнгатуллина – режиссер, Миләүшә Хәммәтова – җыештыручы. Вазыйфалары төрле булса да, бер кулдан, җәһәт кенә эшлиләр. Шуңа күрә эшләре дә гөрләп бара.

– Гөлнара белән серләребез бик тә килешә. Икебез дә бер-бер артлы «Иң яхшы мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек булдык. Премияләр алдык, – дип, сөенечен дә уртаклашып алды йорт хуҗасы.

– Әле ярый кызларыбыз бар. Алар – безнең авылның тоткасы, – дип мактый халык та үзләрен.

Мәдәният йорты булгач, беренче чиратта җырлап, биеп, күңел ачып кына яшиләрдер кебек күз алдына килә, әлбәттә. Анысының да кимен куймыйлар. «Асылъяр» фольклор ансамбле репертуарын яңартып кына тора. Район, республика буенча үткәрелгән бәйгеләрдән бүләксез кайтмыйлар. Ә болай эшләгән эшләре тау кадәрле: түбәтәйләр, калфаклар тегәләр, бәйлиләр, чигәләр. Кыскасы, мәдәният йортындагы байлыкны күреп, авыл халкының ни-нәрсә белән шөгыльләнгәнен шундук чамаларга була.

Милли гореф-гадәтләрне саклау буенча да зур эшләр башкарыла Татар Баганалысында. Кызлар әйтүенчә, иң зур Сабан туйлары, хәтта күрше авыллар акчасызлыктан аптырашып яткан да да, аларда үткәрелә икән. «Авылдашлар бик бердәм, ярдәм итәргә генә торалар», – дип сөенәләр. Авыл халкына кирәк дигәндә, кызлар өчен эшнең вак-төяге юк. Карга боткасы бәйрәмен оештырырга җыенсалар да, зәвыклы, милли күлмәкләрен киеп, беренче чиратта үзләре урам буйлап чыгып китәләр икән. Нәүрүздә дә шулай. Кодаларны каршы алу, кияү мунчалары – барысы да элеккечә бу авылда. Чишмә бәйрәмен дә ел саен үткәрәләр. Самавырлар, тәм-томнар алып төшеп, рәхәтләнеп чәй эчәләр.

Гаиләләрендә дә тәртип кызларның.

– Әле ярый ирләребез сабыр. Безнең шулай көннәр буена «югалып» торуыбызга сүз дә әйтмиләр, – дип шаяртып та алдылар.

Тик авылдагы эштән клубка китеп кенә котылып булмый инде анысы. Балалар үстергәннәр, оныкларга булышалар, терлек-туарны хәзер дә асрыйлар. Гөлнара 32 ел каенана белән яши. Быел аның 90 яшьлек юбилеен бәйрәм иткәннәр. Юбилей дигәннән, авылда бу бәйрәмне һәркем өчен зурлап үткәрәләр.

Яшьлегем хатирәсе

Татар Баганалысында чигелгән культъяулыкларны хәтта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов та кабул итеп алган. Авылда бу хакта горурланып сөйлиләр. Узган ел җитәкчеләребез Чистай Сабан туена килгән булганнар, шунда җаен тапканнар икән.

– Элек кызлар бирәләр иде. Яшь чаклар искә төшеп китте әле, – дигән Рөстәм Нургалиевич һәм культъяулыкны бик кадерләп, күкрәк кесәсенә салып куйган.

Татар Баганалысында культъяулык чикмәгән кеше юк, диләр. Һәр кеше үзе əзерләгән бүләгенә күңел җылысын сала. Саҗидә апа Гыйльфанова, мәсәлән, «Җиңеп кайт!» дип язып куйган. Аның улы махсус хәрби операциядә. Әлегә бүләк иясенә барып кына җитә алмаган. Кыр батырларына да бар мондый культъяулыклар. Аларына «Икмәк – ил байлыгы!» дип язып куелган.

Чигелгән әйберләр Сабантуйларда да төп бүләк икән Татар Баганалысында. Киленнәр инде, аякны нык терәп, сөлге бүләк итсәләр, кызлар оялып кына культъяулыкларын тәкъдим итәләр. Батырлар бетмәгән бит әле авылларда. Араларында егетләр дә бар. Кем белә, борынгы гадәт буенча, насыйбы да чыгып куяр.

Халык ядкәрләре

Мәдәният йортында урнашкан музейны шулай атаган алар. Исеме, чыннан да, җисеменә туры килеп тора. Беркөнне шулай уйлашканнар да, өйдән-өйгә кереп, борынгы истәлекләр җыярга киткәннәр.

– Дөресен генә әйткәндә, бик шикләнгән идек. Булмастыр инде, кирәге юк дип, ташлап бетергәннәрдер дип уйладык, – ди Гөлнара. Бөтенләй киресенчә килеп чыккан. Берәүләр очырмадан алып төшкән, икенчеләре сандык төбен актарган. Нәтиҗәдә шактый гына экспонат җыелган.

> Менә бу тегү машинасына – 120 ел, – ди Венера. – Халидә апа Сафиуллина бүләк итте. Башта каенанасы күлмәкләр тегеп, авыл халкын киендергән булган. Аннары бу эшне Халидә апа дәвам итте. Монысын без дә хәтерлибез әле. Музейга дип бирүен бирде, әмма шул ук көнне каенанасы төшенә кергән: «Ник нигезне таркатасың?» – дип ризасызлыгын белдергән. Халидә апа, үзе килеп, каенанасы ризалыгын сорап, догалар укып китте.

Татар Баганалысы үз рекордчылары белән дә дан тота. Иң озын кеше, иң кыскасы, яше, карты, авыры, җиңеле, иң күп балалы, иң күп терлек асраучы... Кыскасы, «иң-иң»нәр китабы болай да калын инде, көн саен тулыланып та тора.

Авыл менә шулай яши. Урамда кеше юк, күңелсез дип тә сөйләнмиләр, бетәбез дип тә зарланмыйлар. Барысы да хәл кадәренчә эшләнә. Бер-берсе өчен янып, хәлләрен белешеп, ярдәмләшеп торалар. Азрак тырышып җибәрсәң, мондый яшәү рәвеше һәр авылның да кулыннан киләдер кебек тоела. Әлбәттә инде, Венера белән Гөлнара кебек башлап йөрүчеләр булса.

– Эштән шактый соң кайтабыз. Өйләрдә ут алынган була инде. Урамнарны күзәтеп барабыз. Утлы өйләр нурлы күзләр кебек. Аларны күргәч, күңелгә рәхәт булып китә. И, Аллага шөкер, исән-саулар икән, авыл яши әле, дип куанабыз, – диләр кызлар.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Автор фотосы

Курчакларга күлмәкләрне дә үзләре теккәннәр.

Белешмә

Татар Баганалысы авылына XVII гасырның икенче яртысында нигез салынган. Халык игенчелек, терлекчелек, он җитештерү белән шөгыльләнгән. Бүген авылда 608 кеше яши. Урта мәктәп, фельдшер-акушерлык пункты, мәдәният йорты, китапханәсе бар. Соңгы елларда бушап калган йортларны башка милләт кешеләре дә сатып алган. Бу, нигездә, юл төзү эшенә бәйле.

УЛЛАРЫН КӨТҮЧЕ ӘНИЛӘР:

«БЕЗНЕҢ БАЛАЛАРНЫ ДОГА САКЛЫЙ»

Алар һәркөн бер теләктә: балам гына исән-сау булсын! Ятсалар да, торсалар да, уйда – йөрәк пәрәсе. Тамагы тукмы, өс-башы бөтенме, ятып ял итәргә җае бармы? Улларын махсус хәрби операциядән көтүче әниләр әнә шулай дип өзгәләнә. Инде бер елдан артык яхшы хәбәр көтеп яши алар. «ВТ» журналисты батыр ул үстергән сабыр әниләрнең хәлен белеште.

Әйткән сүз – аткан ук

Әлки районының Карга авылында гомер итүче Миңнегөл Галиуллинаның улы Рәмис бер ел элек үз теләге белән махсус хәрби операциягә киткән.

– 2022 елның июлендә улым, безгә әйтеп тә тормыйча, Ватанны сакларга китеп барды. Бер ай узгач кына кайда икәнен хәбәр итте. Ул чакта кече улыбыз Фәнил армиядә калды, – дип сөйли Миңнегөл апа. – Гел еларга гына торам. Шалтыраткан саен, әни, елама, алайса, башка элемтәгә чыкмыйм, дип ачулана. Мине бер дә елатасы килми үзенең.

Миңнегөл апа белән Рәмиснең мәктәп еллары турында сөйләшәбез. Егет оста биюче булган. Сыйныфташлары белән «Йолдызлык» бәйгесендә катнашып, җиңү яулаганнар.

– Балаларымның үскәнен сизми дә калдым. Әле кайчан гына Рәмисне алып кайткан идек. Аны әбисе бик яратты. Бер дә яныннан җибәрмәде. Кая барса да, гел ияртер иде. Беренче онык иде бит. Шуңа күрә тәмле ризык та аңа эләкте. Бик кадерле бала булды ул, – дип искә ала Миңнегөл апа. – Математиканы бик яратты. Башка дәресләреннән өй эшен эшләмәсә дә, монысын ялт итеп әзерләп куя иде. Тугызынчыны бетергәч, Казан автотранспорт техникумына укырга керде. Бер ел укыды да армиягә китте. Фикере нык иде: ир-атның хәрби әзерлеге булырга тиеш! Шуңа күрә махсус хәрби операциягә үз теләге белән китеп баруы да гаҗәп түгел.

Рәмис кечкенәдән әйткән сүзендә тора торган була. Өйләнгәндә дә әтиәнисен аптырашта калдыра ул. Армиядән кайтып, Казанга эшкә урнаша да өйләнергә карар кыла.

– Икесе дә яшь иде. «Ничекләр яшәп китәрсез?!» – дисәк тә, сүзләре нык булды. Матур гына гаилә корып җибәрделәр. Арчага барып төпләнделәр. Гөлинә киленем белән ике бала үстерәләр. Кызлары быел беренчегә барды, малаебызга 4 кенә яшь әле. Киленебез дә батыр йөрәкле. Ире янына ике тапкыр барып кайтты инде. Кучтәнәчләр илтте, – ди Миңнегөл апа. – Рәмис взвод командиры урынбасары, элемтә бүлеге командиры булып хезмәт итә. Күптән түгел аңа «Батырлык өчен» һәм «Махсус хәрби операциядә катнашучы» медальләрен тапшырдылар. Нинди батырлык эшләгәндер, анысын әйтмәде. Медаль биргәннәрен белгәч, горурландым, күңелем тулды. Рәхәтләнеп еладым. Чын ир-ат итеп тәрбияләгәнбез икән.

«Яңача яши башладым»

Арчада гомер итүче Фирадия Фәсәхиева әнә шулай ди. Ул да ике улының исән-имин әйләнеп кайтуын көтә.

– Хәзер инде элеккечә ашаганым, элеккечә йоклаганым юк. Телефонга ят номердан шалтыратсалар да, йөрәгем дерт итә. Тормышым бөтенләй үзгәрде. Яңача яши башладым. Ятсам да, торсам да, бер генә уй – балаларым исән-сау булсын, – ди Фирадия апа. – Улларым бик йомшак күңелле булып үсте. Кешегә каты бәрелә белми алар. Икесе дә Чечнядә булдылар. Олысына – 51, кечесенә – 47. Башта Илнарны чакырдылар. Ул вакытта өлешчә мобилизация турында беринди хәбәр юк иде әле.

Элек полициядә эшләгән Ленарга повестка577ны сентябрь ахырында тапшыралар. Моңа кадәр зур сынаулар кичерергә туры килә аңа. Өч ел элек яман чирдән хатыны үлеп китә. Бу хәсрәтне бик авыр кичерә ул. Ике баласы бар булган юанычына әверелә.

Фирадия апага 73 яшь. Бик тыныч сөйләшә. Аралашканда аның никадәр сабыр икәненә сокланасың. Язмыш төрлечә сынаган аны. Ире белән озак яши алмаганнар. Юллары аерылган. Балаларны кеше итәр өчен шактый көч түккән ул. Сынаулар эзсез калмаган. Йөрәгенә катлаулы операция ясаганнар. Озакламый тагын йөрәген күрсәтергә барасы бар икән.

– Ленарым турында кайгылы хәбәр китерделәр. Шул хәбәрне ишетүгә мин дә беттем. Соңрак исән икәнен әйттеләр. Илнарым каты яраланган. Аны миңа сиздермәделәр. Әле ярый кызым Алинә абыйларының командиры белән сөйләшеп, хәлләрен белешеп тора. 40 яшемдә тапкан Алинәмне, бәхетемә алып кайтканмын икән, дим. «Әнием» дип өзелеп тора. Мине кадерләп яшәтә, мин борчылмасын дип тырыша, – ди Фирадия апа. – Елаган чакларым да була. Әмма аны кешегә күрсәтмим. Йөрәк белән еларга да өйрәндем инде. Җебеп киткән чакларда үземне сүгеп ташлыйм. «Син, Фирадия, көчле хатын идең бит, балавыз сыгып торма әле, бирешмим, дип яшә», – дим. Миңа – балаларым, аларга мин кирәк. Шуны искә төшереп, тынычланырга тырышам. Яшәргә кирәк бит! Моңа кадәр бар теләгем кабул булды. Бар әниләргә дә газизләре белән очрашулар насыйп булсын иде!

«Мин еламыйм»

Кама Тамагында гомер итүче Резедә Әсхәдуллинаның ике улы да махсус хәрби операциядә. 2022 елның 28 сентябрендә 25 яшьлек Айратка повестка килеп төшә. Армия хезмәтендә булган егет, барам, ди. Әниләре әйтүенчә, алар ил өчен барысын эшләргә дә әзер егетләр булып үсә. Тыңлаган әкиятләре дә, караган кинолары да, ятлаган шигырьләре дә геройлар турында була. Ике уллары да кечкенәдән, мин батыр булам, дип үсә. Туганлык җепләре көчле. Айратка повестка килүгә, абыйсы Артур да шунда ашкына. «Энем анда булганда, мин ничек монда калыйм?!» – ди.

– Артур бер айдан китеп тә барды. Башта повестка килмәсме дип көтте. Аңа дигәнен Мәскәү аша җибәргәннәр икән. Соңрак килде ул. Ул чакта инде Артур махсус хәрби операция зонасында иде. Аларның бу адымын аңлап кабул иттем. Еламадым. Әле дә еламыйм. Бары тик догада торам. Улларым шалтыратканда телефонның тавышын ачып куеп, сүрәләр укыйм. Барлык мөселман егетләре тыңлап тора икән. Бисмилласыз йөрмәгез, дип кабатлап торам, – ди Резедә апа.

Айрат белән Артур – икесе ике якта. Бер дә очрашканнары юк икән. Артур яраланып, берничә мәртәбә операция дә кичергән. Хәрби бурычын үтәгәндә кыюлыгы өчен «Батырлык» ордены белән бүләкләнгән.

– Кече улым да яраланды. Ядрә кыйпылчыгы тәненә эләксә дә, эчке органнарга зыян салмаган. Табиблар бик гаҗәпләнгән инде. Ә мин исә, улымны Аллаһы Тәгалә саклап калды, дим. Укыган догаларым кабул булгандыр. 15 ел элек динебез кушканча яши башлаган идем. Менә хәзер догалар белү, ышану һәрнәрсәне дөрес кабул итәргә өйрәтә, – ди Резедә ханым. – Быел уллары махсус хәрби операциядә булган бер төркем әти-әни белән изге хаҗ сәфәренә бару насыйп булды. Корбан чалдырып, улларыбыз саусәламәт кайтсын, дип догалар кылдык.

Резедә Әсхәдуллина әйтүенчә, махсус хәрби операция, бүгенге сынаулар кемнең кем икәнен яхшырак аңларга ярдәм итте.

– Бер-береңә терәк булу, булышуның ни икәнен искә төшердек, – ди ул. – Үзем дә көчле булырга тырышам. 63 яшьтә дип тормыйм, волонтерлык белән шөгыльләнәм. Маскировка челтәрләре әзерлибез.

...Тугыз ай буе карынында йөрткән, кадерләп үстергән, салкыннарда туңдырмаган, эсседән саклаган сабыйлар инде илне сакларлык ир-егетләр булып өлгерсә дә, алар әниләре өчен иң элек бала булып калалар. Елыйсы килгәндә дә елмаерга өйрәнгән әниләр сер бирми. Үзе мондый сынаулар күрмәгән буынның газиз балаларын сагынудан чәчләре агарса да, куенына алып бер кочарга, иркәләп назларга тилмерсә дә, улларының илен, Ватанын саклаулары белән горурлана бу изге затлар. Бөркеттәй егетләр үстергән әниләр шундый инде алар!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ӘЛФИЯ МИҢНУЛЛИНА:

«ӘТИ БЕЛӘН ӘНИ ХАЛЫК ЯРАТУЫН ТОЕП КИТТЕ»

Туры сүзле, кыю, хәтта ки дуамал да. Шул ук вакытта чайпалырга торган нечкә күңелле. Сүзебез – Әлфия МИҢНУЛЛИНА хакында. Соңгы вакытта аңа Туфан Миңнуллин варисы буларак авторлык хокукларын якларга туры килә. Моның сәбәпләре нәрсәдә? Театр, әдәбият өлкәсендә нинди мәсьәләләр борчуга сала? Шәхесләрнең балаларына багышланган әңгәмәләрнең бүгенгесе әнә шул хакта.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Күпмедер тынлыктан соң театрлар янә Туфан Миңнуллин әсәрләрен искә төшерде. Кайчан гына Курчак театры «Әлдермештән Әлмәндәр»не чыгарса, Әлмәт театры быелгы сезонын «Ат карагы» белән ачып җибәрде. Туфан абыйга кайту – замана таләбеме, әллә башка сәбәпләр дә бармы?

– Бәлки сагынганнардыр... Мин театр белгече түгел, шуңа күрә бу сорауга төпле җавап бирә алмам. Спектакльләрне ничарадан бичара, әти хокукларын яклау максатыннан карап барам. Аннан тәрбия дә үзенекен итә. Кечкенәдән әти-әни театр дөньясы белән таныштыргач, кая гына барсам да, театрда спектакль карарга тырышам.

:: Соңгы премьераларны – «Әлмәндәр»не, «Ат карагы»н искә алсак, сез ул куелышлардан канәгатьме?

– Мин әле Чаллы театрында «Диләфрүзгә дүрт кияү» спектаклен дә карадым. Ул да – быелгы сезон премьерасы. Өч төрле режиссерның өч төрле эше. Әлмәт театры спектакле турында фикеремне мин инде язма рәвештә дә әйттем. Хәзер дә фикерем үзгәрмәде. Шундый тенденция бар: мин аны автор текстын мыскыл итү дип атыйм һәм ул татар режиссерларына гына карамый, дөнья күләмендә дә бара. Голливуд сценаристларының ярты елга сузылган забастовкаларын гына искә төшерик... Әйтерсең авторның язганы берниндиә әһәмияткә ия түгел, режиссерга аның исеме һәм персонажлары гына кирәк. Нәтиҗәдә эти персонажлары белән бөтенләй башка әйбер туа. Пьесаны танып та булмый кайбер вакытта. Авторның вәкиле буларак, бу миңа Туфан Миңнуллинның популярлыгына сыенырга маташу кебек күренә. Бер яктан, әтинең әсәренә карата хөрмәтсезлек минем ачуны китерә. Икенче яктан, татар кешесе буларак, бик пошаманга сала. Ник дигәндә, мәктәпләрдә татар әдәбияты укытылмый, татар теле ташка үлчим дәрәҗәсендә генә бирелә. Шуңа күрә яшьләр Тукай белән Муса Җәлилне ишетеп белсә, афәрин дип әйтергә мәҗбүрбез. Ләкин бит алар башка авторларны белмиләр. Театрда әсәрне шушылай тураклап биргәч, яшьләр аны автор шулай язган дип кабул итә. Алга таба нишләргә, әсәрне ничек яшь буынга җиткерергә? Мин әнә шул хакта уйланам. Берничә идея бар иде. Бернишләп тә булмый, хәзер күпчелек аудиокитаплар тыңлый. Аннан соң татарча укый алучы яшьләр дә азайганнан-азая. Шуңа аудиоверсия яздыру идеясен Камал театрына да тәкъдим итеп карадым, тик ул барып чыкмады. Татарстан китап нәшрияты аудиокитаплар яздыруны башлап җибәргән иде, ул да тукталды. «Китап» радиосы әсәрдән өзекләр бирә бирүен, ләкин анда күбрәк заманча әдәбият өстенлек итә. Ә ул бик чуар хәзер...

> Хәзерге вакытта театр – әдәбиятны күрсәтә алырдай бердәнбер урын. Әгәр дә режиссерлар ул әдәбиятны шушылай болгатса, чалса, тамашачы аннан нәрсә алып китәчәк? Минем карашка, театрга шундый зур бурыч куелган вакытта, төрле тәҗрибәләр кече зал форматында калса гына ярыйдыр.

Чаллы театрында «Диләфрүз...»не карадым дидем бит әле, анда мин текстка хөрмәт сиздем. Режиссер Олег Кинҗәгулов аны махсус ретро стилендә эшләгән, шул ук вакытта заманча спектакль туган. Режиссерның кызыклы табышлары да бар, әмма бу табышларга автор тексты комачауламаган.

«Әлдермештән Әлмәндәр» турында. Мин Камал театры Әлмәндәре кабатланмас, аны башка куеп булмый, дигән фикер белән килешмим. Аны куярга омтылышлар булды, хәтта мультфильм да төшереп карадылар. Аның тарихы озын, башлануы да конфликтлы булды. Әлмәндәр космоска да очарга тиеш иде анда, Бөек Ватан сугышы ветеранына да әйләндергәннәр иде. Минем бу очракта да позиция бер: әгәр башка әсәр кирәк икән, аны язарга язучылар бетмәгән бит. Нәрсәгә әсәрне бозарга? Монда да шул ул исемне файдалану, русча әйткәндә, «примазаться к чужой славе» шәйләнә. Ахыр чиктә без текстны бозмаска, Әлмәндәрне космоска очырмаска һәм Туфан Миңнуллин әсәре мотивлары буенча бирергә дип килештек. Мультфильмны алар миңа күрсәтәбез диделәр, күрсәтмәделәр. Шуңа күрә, өзеп, нинди дер фикеремне әйтә алмыйм.

«Әлдермештән Әлмәндәр»не мин тагын Туймазы театрында карадым. Ул без күреп ияләшкән Камал театры спектакленә гомумән охшамаган иде. Мәсәлән, Равил Шәрәфиев уйнаган Әҗәл белән Туймазы театрындагы Әҗәл – икесе ике төрле чишелгән образлар. Ул Әлмәндәрнең үзен алдаганын да аңлый, ләкин уенны дәвам иттерә. Әлмәндәр дә Шәүкәт абый Биктимеров тудырган образны кабатламый. Хәтта сәхнә бизәлеше дә үзгә. Ә бит бу спектакльгә алынганда, күпләр сәхнә бизәлеше ягыннан да Камал театрын өлге итеп ала. Илгиз Зәйнинең «Әлмәндәр»енә килгәндә, ул аны ностальжи формасында куйган һәм аны яшерми дә. Ул шуның белән кызыклы да. Аннан соң, курчак театрының мөмкинлекләре дә башкача. Анда тылсым күбрәк димме. Кыскасы, мин дә Илгиз белән бергә сагындым, яратып карадым.

:: Сөйләшенгән кадәренә йомгак ясасак, Туфан абый әсәренә алынганда, нәрсә эшләргә ярамый? Гомумән, классика белән ничек эшләргә кирәк?

– Туфан Миңнуллины үзе исән чагында ук классиклар дәрәҗәсенә күтәрделәр. Әсәр кайчан классикага әйләнә? Әгәр анда күпчелекнең күңеленә хуш килгән фикер-идеяләр ятса, берничә буын кеше яратса. Ул идеяләрне чит идея белән алмаштырырга ярамый. Аның фикерен алып, үзеңнекенә алыштыру – тәртипсезлек хәтта. Моңа каршы миңа болай диделәр: «Хәзер театрга ак яулыклы әбиләр йөрми, яшьләр килә. Аларга экшн кирәк». Бәл-

ки театрларда ак яулыклы әбиләр йөрерлек спектакльләр куелмыйдыр? Мин каршы түгел, экшн да куелсын, триллер да, башкасы да. Әмма ул экшнны ниндидер әсәр өстенә язарга түгел, яңабаштан башка кеше язсын. Яңа әсәр тусын. Шуңа күрә әйтергә мәҗбүр булдым: режиссер Айдар Җаббаровка Туфан Миңнуллин әсәрләрен куярга башка рөхсәт бирмим. Бу фикерне ТАИСка да җиткердем. Дөрес, ул – искиткеч талантлы егет. Ләкин аның кыйбласы юк. Һәм аңа бу җәһәттән ярдәм итүче дә юк бугай. Без баштан ук аның белән уртак тел таба алмадык. «Агыла да болыт агыла» спектакленнән соң, бу егетне яклап, мине надан, аңгыра, артта калган кеше итеп калдырдылар. Ә бит спектакльнең 80 проценты – Туфан Миңнуллин пьесасы. Теләгән кеше әтинең китабын алып, үзе дә чагыштырып карый ала. Пьеса Хәсән Туфан турында булгач, табигый ки, анда шагыйрьнең шигырьләре бар. Бу спектакльдә артистлар Хәсән Туфанның иң танылган шигырьләрен укыйлар. Шуннан афишага авторлар дип Хәсән Туфан һәм Туфан Миңнуллинны язып куялар. Ә бит пьеса Хәсән Туфан вафатыннан соң дистә еллар үткәч язылган. Бу ничек була, Хәсән Туфан, кабереннән чыгып, әти белән утырып, пьеса язган булып чыгамы инде? Яшь кеше тәҗрибә ясый, син аңламыйсың, диләр. Шуннан шагыйрьләр турында башка спектакльләрне искә төшерәм. Әтинең Муса Җәлил турында «Моңлы бер җыр», Тукай турында «Без китәбез, сез каласыз» дигән пьесалары бар. Икесендә дә шагыйрьләрнең шигырьләре кулланылган. Әмма ике спектакльдә дә Сәлимҗанов авторны «Муса Җәлил, Туфан Миңнуллин», «Габдулла Тукай, Туфан Миңнуллин» дип куймаган. Чөнки бу абсурд булыр иде. Театр «Агыла да болыт агыла» спектакле буенча шуңа барып җитте: урамдагы айлык афишадан Туфан Миңнуллин исеме алып атылды.

Закон буенча, әсәргә автордаш килешү нигезендә генә кертелә ала. Әлеге килешү автор белән, әгәр инде автор исән булмаса, варислары белән төзелә. Мин андый килешүгә кул куймадым.

Бәлки кайбер очракта дәшмичә калырга да кирәктер. Мин инде шундук фикер әйтәм һәм ишетмәгәнемне ишетәм.

:: Ишегалдына килеп кергәч тә афиша, Туфан абый портреты каршы ала. Без сөйләшкән бүлмә – Нәҗибә апа бүлмәсе, аның портретлары, шәхси әйберләре... Иҗатлары файдаланылды, хәзер дә файдаланыла, ә шәхес буларак игътибар бармы аларга?

– Әлләни кызыксыну тоймыйм. Бу мәсьәләдә миңа, үзең ник йөрмисең, дип шелтә белдерүчеләр дә бар. Әти вафатыннан соң мин шактый гына актив рәвештә эшләп алдым. «Син үзеңә исем ясарга тырышасың, шуның белән акча эшлисең», – дип гаепләүләр дә булды. Башта моңа шок хәлендә идем, аннары юмор белән карый башладым. Ләкин канатым сынды, активлыгым сүрелде. Хәзер янә: «Ник музей ясамыйсың, ник кайгыртмыйсың?» – диючеләр бар. Мин болай уйлыйм: әтинең дә җитешсезлекләре булгандыр, ләкин ул гомер буе хәләл акчасына яшәде. Ул нык лоббист иде. Хәтта «глава»ларның: «Туфан абый, син әйт инде, без әйтсәк, таякның авыр башы безгә төшә», – дип, үтенеч белән килгәннәрен кайтып сөйли иде. Әти начальство янында тегеләрнең проблемаларын күтәрә һәм ул хәл ителә иде. Моннан аңа файдасы булса, бер капчык бәрәңге булгандыр. Ул акчага бернәрсә эшләмәде. Аның йорты, фатиры – барысы да хәләл акчасына булдырылган. Чөнки спектакльләре куелды, китаплары чыгып торды.

Мин, кызлары буларак, аларның каберләрен тәртиптә тотам. Ашларын үткәрәм, сәдакасын бирәм. Әтинең Кама Тамагындагы музеена шактый күп әйбер бирдем, шул исәптән кыйммәтле әйберләрне дә. Мәсәлән, әти үзе уйнаган тальян гармунны. Ә әтинең кул белән чигелгән сөлгеләр коллекциясен музейчылар хәтта туган як музее экспозициясенә куйганнар. Туфан Миңнуллин китапханәсен туган авылы Мәрәтхуҗа клубына бүләк иттем. Әтинең туган авылындагы утарын, бер тиен алмыйча, музей ясар өчен тапшырдым. Казанның кызлар гимназиясенә, Чаллыдагы гимназия музейларына әтинең шәхси әйберләрен бирдем. Алга таба да, шундый инициатива белән чыгалар икән, ярдәм итәргә әзермен.

Әти гомер буе татар халкы, татар театры, татар мәдәнияте дип чапты. Ну бераз чапсыннар инде хәзер алар да. Әмма чабучы юк. Әни инде исән чагында ук онытылды.

Минем аңа: «60 ел театрдан кайтып кермәдең, хәзер беркемгә кирәк түгелсең, миңа калдың», – дигәнем булды. Ул сүзсез елый иде. Ник шундый сүз әйттем дип, мин дә елый идем *(елый)*. Исән чакта кирәкмәгәнне хәзер кемгә кирәксен?

Яшьрәк чакта театр альбомнарын кызыксынып карый идем. Аларның барысы да диярлек Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская сурәте белән башлана. Мин әнидән: «Бу актриса хәзер кайда, кабере кайда?» – дип сорый идем. Картайган көнендә шул ук артистлар авыруы – деменция белән авырый да аны интернатка илтеп ыргыталар. Шунда караучысыз, игътибарсыз үлә ул. Инде театрның легендасы да кирәкмәгәч, Нәҗибә Ихсанова кирәкми дә кирәкми.

Мин шунысына сөенәм: әти дә, әни дә исән чакта халыкның яратуын күреп, тоеп киттеләр. Әнине, авырып, инде танырлыгы калмаган кыяфәттә дә урамда таныйлар иде. Ул шуңа ихластан сөенде. Артистка шул кирәк бит инде аңа.

:: Үзегезнең истәлекләр язасыгыз килмиме?

– Язучы язмыйча тора алмый, диләр. Ә мин тора алам. Кайсы вакыт әче итеп язасы килә. Шул вакытта шигырь язганым бар. Ул шигырьләрне Илсөяр Иксановага күрсәткәнем булды, ул яхшы бәяләде. Бәлкем минем күңелне күрер өчен әйткәндер. Тәмамланмаган берничә пьеса бар. Язу дигәннән, әти матбугатта «Кызыл тышлы дәфтәрдән» дигән цикл алып бара иде. Ул «Утырып уйлар уйладым» дигән китап булып та чыкты. Менә шул стильдә язасым килә. Бәлки тора-бара булыр да әле ул.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ӘҢГӘМӘ ТУЛЫСЫНЧА VATANTAT.RU САЙТЫНДА

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ШУНДЫЙ ИНДЕ БЕЗ...

(Бәян)

< Дәвамы. Башы 15, 22, 29 сентябрь, 6 октябрь саннарында

Кафил агай аны ерактан ук сәламләде.

– Гуртта үскән димәссең, җилдән җитез син, – дип мактагач, учына төкереп, тәмәкесен сүндерде дә: – Шәкүрәттәй йомыш та куштымыни? – диде. – Хәйләкәр дә соң корткa! Бүген без икәү генә, әйдә, кабинага чум, Илдус бырат!

– Ялгыз карчыкка көн итүләре читендер.

– Әһе, ялгыз ди сиңа! Аның гуртта улы белән кызы, өчме-дүртме оныгы яши. Олавы белән тәҗел әйберләрен кайтарып аудар! Малае хатыны кубызына биесен дә ди, кызы анасы турында кайгыртырга тиештер бит! Каты бәгырьле Айлия.

Шофер бүтән Айлияне тиргидер, Мирзам белгән, Мирзам сокланган кыз мәрхәмәтлелек тукымасы белән тукылган изге җан иде. Аңамыни анасын чәй-шикәргә тилмертү!

Күпер башында кырлы эшләпә кигән карт утыра, ул тактага чиләк-чиләк бәрәңге, кишер, чөгендер тезгән иде.

– Кем ул? – диде егет, кызыксыну шулай ук чир иде.

– Һай, күк белән саташкан Хәсән карт инде! Тагын калдык-постыгын сата. Кемгә хаҗәт аның туфраклы бәрәңгесе дә балчыклы чөгендере! Базарда һәммә нәрсә чип-чиста. Тастымал белән сөрткәннәр диярсең, хет юмыйча аша.

– Нужа саттыра микән? – Бу сүзне Мирзам теге чакта ук откан, татайлар: «Нужа куабыз», – дип сөйләргә ярата иде.

– Нинди нужа?! Тәкәбберлек! Минеке агусыз, янәсе. Бишек баласына ашатсаң да зыянсыз, янәсе. Аның ике улы – Рудия күләмендә танылган авиаконструкторлар. Москитта эшлиләр. Башлы нәсел үзләре. Хәсән бабай төмсә, беркем белән аралашмый, беркемгә ягылмый. Аның дөньясы – күк. Әкәмәт инде, калхуз чорында агроном Әхсәннең канын эчте, син – халык дошманы, кыр-басуларга агу сибәсең, ди. Утыз сигезенче еллар булса, Әхсәнне аталар иде. Агусыз гына ничек чүп үлән белән көрәшмәк кирәк! Бичәләрегез утасын, дигән бабаң. Утарырсын безнең катыннардан!

– Нишләп кырларыгыз ялангач, Кафил агай?

– Кем сөрсен дә кем чәчсен! Өч ел элек калхуз таралды. Инвестор дигәнең белән мантымадык, ике мең баш савым сыерын төядә дә качты! Ишеттем әле, элгәре бабасы Себергә куылган кулак Әнәс оныгы безнең якларда иснәнә, ди. Шул малай нәрсәдер кайнаштырмакчы бугай. Хәер, син – хур җитәкчесенә болар пычагымамы? Сезнең бит күңел юанычыгыз җыр-бию, едритлар!

...Базар җәйрәгән, капка төбендә дә капчык-капчык тауар өйгәннәр иде. Кафил, күзлеген киеп, кесәсендәге кәгазен укыды:

– Бәрияттәйгә биш кила бәрәңге, ике кап тоз, дүрт кила писүк. Дамир бабайга кәбестә, эре токмач. Син бар, хур җитәкчесе, Шәкүрәттәйнең заказларын үтә. Кырык минут вакыт сиңа!

Мирзам яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр рәтеннән китте. Чынлап та, тастымал белән сөрткәндәй, алма-грушалар ялтырый, юылган кишер, чөгендер, баш хәтле кәбестәләр тузан бөртеге дә кундырмыйча биек-биек агач-куакларда үскән сыман иде. Фатир хуҗасы сөенсен: һәммәсен дә әз-әзләп алыйм дигәндә генә егетнең беләзегендә яшел төймә чыелдады. «Тия күрмә, агулану дәрәҗәсе югары» дип кисәтә иде ул. Ни-нәрсәгә генә кагылсаң да, «яшел күз»гә ошамады. Ахырдан Мирзам бәрәңгегә әрҗәсенә иелде. Тавык йомыркасы төсле сап-сары, йом-йомры «җир алмасы»н саткан хатын:

– Ярмалы, бик тәмле, – дип мактаса да, «төймә» чыелдавын белде.

Кафил агай әрҗәсен тутырган, машинасы янында чүгәләп дөнья тамаша кыла иде, ике кулын селкеп килгән егеткә:

– Бәрәч, нишләп буш син? – диде.

– Кайсына гына орынма, агулап үстерелгән.

Шофер бот чабып көлде:

– Ну сез гурт халкы! Синең кайда чиста ризык күргәнең бар?

– Бездә... – Мирзам үзенең Җирдә икәнен онытып җибәрде.

– Кайда ул сездә?

– Бездә... Әбинең бакчасында. Хәерсез, адым саен ялган!

– Һе, әбисендә икән! Соң, бырат, шушы тиклем миллионлаган авызга кортканың ике-өч түтәл кишер-чөгендере генә җитәмени?! Әнә телевизордан күрсәттеләр, Себер ягында митайлар безнең җирләргә ташкабак утырткан. Корткыч бөҗәкләр яфракларын тишкәләмәсен өчен дуст өрдерттәләр. Противогаз киеп! Ап-ак тузан болыты кырда! Ашыйбыз, нишлисең!

– Нинди зур бәрәңге бакчаларыгыз елап ята, агай. Һәркем үз тамагын үзе кайгыртсын!

– Ята, дөрес. Калорад коңгызы белән көрәшеп ардык без, хур җитәкчесе. Хет дару сип, хет артыңны туңкайтып чүплә, файдасыз, минут саен үрчи, буйбуй ыштанлы кабахәт! Ну, нәрсә, Шәкүрә карчыкка шымытырмы инде?

– Хәсән карт өргәсендә туктарсың, агай.

–3–

Галиб хәбәр көтте. Һай, пырдымсыз! Мирзам әле генә Җиргә кунаклады. Бурычымны үти алырмы яисә яшь парларны сайларлык тәҗрибәсе җитәрме дип хафаланмый, Оныкка ышана Хуҗа, юксыну йөрәкне телгәли иде. Юксыну... Центаврда сагыш-сагынулар юк, ә аңарда бар, чөнки Галиб... Чү, кузгатма, кирәкми! Бу юлысы Мирзамның сәфәре айларга сузылыр. Бәлки ул кыскарыр да. Вакыт озынлыгы егеткә бәйле: әгәр Онык тимерне кызуында сукса, күрешү сәгатьләре бик тиз якынаер.

Шушы төштә Галибнең уйлары бүленде: чәчен баш түбәсенә су тамчысы тамса тәгәрәп төшәрлек итеп ялтыратып кырган Мангуш күренде. Ул да боек иде.

Дәвамы бар >

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына **«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»** газетасына языл

2–23 октябрь – ташламалы бәядән язылу көннәре

П2435 (җомга) >> ~~571 сум 98 тиен~~ **497 сум 34 тиен**

П2409 (сиш., чәрш., җомга) >> ~~1255 сум 86 тиен~~ **1086 сум 18 тиен**

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040

info@vatantat.ru

420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана. 26 октябрьдә уйнатылачак бүләк –

10 кг шикәр комы

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

Бу атна җиңүчесе – Буа шәһәрендә яшәүче Мәүлетшина Фәния. Котлыйбыз һәм элементәгә чыгуыгызны үтенәбез!

Әз-мәз мәзәк

– Ә ни өчен нәкъ менә фортепианоны сайладыгыз?
– Башта скрипкада уйный идем. Әмма чәй салган стаканым аннан һәрвакыт төшеп китә иде.

***

– Нәрсә ул позитив фикерләү?
– Әйтик, сез баскычтан егылып төшәсез һәм «Карале, ничек тиз төштем бит, әй», – дип шатланасыз.

***

Әгәр язмыш сиңа мине бүләк иткән икән – шуны бел: сюрпризлар әле башлана гына!

***

– Нишләп кулыңны кесәңә тыгып, берни эшләми йөрисең?
– Эшкә урнашканда: «Сездә татарлар эшлиме?» – дип сорадым, «Юк», – диделәр.



Беләсең килсә...

1 Фелинотерапия ул:
а) филләр белән дәвалау;
б) песиләр белән дәвалау;
в) этләр белән дәвалау.

2 Боулинг уенының иң популяр төрендә ничә кегль кулланыла?
а) 6;
б) 10;
в) 12.

3 Татар шагыйре Рәшит Әхмәтҗанов үзенең туган авылында башта кем булып эшләгән?
а) ташчы;
б) тимерче;
в) көтүче.

4 Себернең иң зур тимер юл вокзалы кайсы шәһәрдә урнашкан?
а) Арцах;
Красноярск;
б) Иркутск;
в) Новосибирск.

Җаваплар: 1.б); 2.б); 3.а); 4.в).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: кала, җәй, ату, карта, болгату, мим, Ак, Угрюм, лак, Ка, ис, Илион, ук, Ту, за, сарык, амхара, мерч, албасты, Саба, алты, он, төр, яр, Лада, Илшат, Окнос, сео, онны, еккам, унина.

Вертикаль: абау, Ансат, исе, Стокгольм, әрлек, ул, Хәбир, шок, Глюкоза, ака, манара, Том, лат, ал, ару, Ус, Бари, очу, Камал, Ялкын, Җамали, ресторан, астыртын, Дорн, йомык, Укчы, Бас.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм масс-сакылам коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 343

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – **газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+